

АЗАТ ХАТЫН

1926 ЕЛДА ЧЫГА БАШЛАДЫ

МАРТ • 1979



8 МАРТ — ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ.

Иң матур бәйрәмнәрнең берсе
яз аена туры килү гаҗәпмени!
Бөтен табигать уянырга, яңарырга,
яшәрергә омтылган чак.
Кулларның гөлгә үрелгән,
йөрәкләрдән җыр түгелгән,
күзләрнең нурга күмелгән чагы.
Күңелләрнең күтәренке, омтылышлы,
теләсә нинди эшләрне дә башкарып чыга
алырлык рухлы чагы бу.
Бөтен дөньядагы хезмәт иясе хатын-кызларның
үз хокуклары өчен көрәшкә,
тынычлык өчен көрәшкә,
балалар бәхете өчен көрәшкә
тагы да ныграк тупланган чагы бу!
Безнең илебездә
март ае
быел икенче бер олы бәйрәм белән дә истә калыр.
Март башында
СССР Верховный Советына сайлаулар булып үтте.
Шаулап, гөрләп үтте бәйрәм,
сайлаучылар совет демократиясенең
тантанасын бәйрәм иттеләр.
СССР Конституциясе кабул ителгәннән соң
иң беренче сайлау булды ул.
Төп Законда язылган
бөтен хокуклар
шушы сайлауда тагы бер тапкыр нурланып балкыды.
Илебез,
халкыбыз алдында күркәм эшләре белән дан
казанган,
дәүләткүләм мәсьәләләрне хәл кыла алырлык
кыю фикерле хатын-кызларыбыз,
партия һәм
хөкүмәт җитәкчеләре белән беррәттән,
иң югары дәүләт органына —
СССР Верховный Советына сайландылар.
Эшләрегез уң булсын,
кадерле дуслар!
Юлларыгызга гөлләр яусын!

Республикабыз зулаган зур уңышларда-промышленность һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендә, фән, мәгариф, культура, халыкның материаль тормышын яхшырту, сәламәтлеген саклау һәм башка өлкәләрдә Татарстан хатын-кызларының өлеше зур. Алар олы ихтирамга лаеклы.

КамАЗны сафка бастырган, Түбән Кама электр станциясен төзүче хатын-кызларыбызның эшчәнлегенә, иркен кырларыбызда мул уңыш үстерүче уңганнарның фидакарь хезмәтенә, уку йортларында, фән учреждениеләрендә укытучы, иҗат итүче галимәләребезнең тырышлыгына, сәхнә осталарыбызның талантына, ак халатлы медикларыбызның сизгерлегенә, түземлегенә сокланмый мөмкин түгел.

8 Март уңае белән аларны — барлык хатын-кызларыбызны чын күңелдән котлыйсы, нык сәламәтлек, зур бәхетләр телисе килә.

Мансур ХӘСӘНОВ,
Татарстан Министрлар Советы
председателе урынбасары.

Алыбыз да безнең, гөлебез дә,
Газизләр сөз безгә гөл генә:
Туган телиең — алты миллионлының —
Алтын Тәпләкәе — сөз генә!
Хәерле юл — сезнең яңа елга,
Хәерле юл — алты елларга.
Мәңгеләшә торган тормыш белән
Яшик әле бергә дөньяда!

Хәсән ТУФАН.

Модельләр ясаучы Люция Гарипова, клепкалаучы Пелагея Бузуева, револьвер станокта эшләүче Евдокия Чканова, электромонтажчы Маргарита Сергеева, термист Әминә Әмирханова, җыючы Анна Кузнецова — безнең авиация производство берләшмәсендә фидакарь хезмәтләре белән дан һәм хөрмәт казанган кешеләр. Ә республикабызда андыйлар тагын күпме!!

Язның беренче бәйрәме — 8 Март көне белән тәбриклим, сезгә, — безнең турылыклы юлдашларыбызга, яңадан-яңа хезмәт уңышлары, гаилә бәхете, кояшлы көннәр һәм сезнең һәрчакта да шулай олы җанлы булып калуыгызны телим!

Галимулла ӘСХАДУЛЛИН,
фрезалаучы, Социалистик Хезмәт Герое,
СССР Верховный Советы депутаты, КПСС өлкә
комитеты бюросы членлыгына кандидат.

*Юлыгызга гөлләр
яусын,*

Газиз сеңелләр, апалар, әниләр, әбиләр! Бәйрәмнәрегез — җырлы, җырларыгыз бәйрәмчә шатлыклы, дәртле, күтәренке булсын! Мин моның шулай икәненә тирәннән ышанам. Татар кызлары элек-электән музыкаль җанлы булганнар. Алар безнең көннәргә кадәр халыкның иң борынгы җырларын саклап китереп җиткергәннәр. Җырларның иң моңлылары кызларның үзенә багышланган: «Галиябану», «Зиләйлүк», «Зөләйха», «Зөлхиҗҗә...» Санап кына бетерерлек мени!!

Язның иң күркәм бу бәйрәмендә күңелләрегезгә шатлыклы яңа җырлар кунуын телим! Ул җырлар тормышыгыздагы борчуларны киметсен, моңнарыгызны таратсын, өметләрегезне яктыртсын! Сезнең йөздәге бәхет нуры исә безгә, композиторларга, яңа җырлар иҗат итәргә илһам бирер.

Нәҗип ҖИҺАНОВ,
композитор, СССР халык артисты, Казан дәүләт консерваториясе ректоры, профессор.

Хөрмәтле аналар! Сезне олы бәйрәмегез белән тәбрик итеп шундый теләкләр әйтәсе килә:

— Соңгы елларда фәнни-техник революция сүзен еш кабатлыйбыз. Ә кешенең аңында, күңелендә, психологиясендә туган үзгәрешләрне сизеп бетермибез. Телевизор, радиоалгыч, матбугат аша килгән киң информациянең белем дәрәҗәбезне күтәрүгә, хезмәткә омтылыш тудыруда йогынтысы зур булды. Әмма материаль мөмкинлекләрнең үсүе кешеләрнең идея, әхлак һәм культура дәрәҗәсе күтәрелү белән даими рәвештә бергә барырга тиеш. Без моңа кадәр иң беренче планга халыкның белем дәрәҗәсен күтәрүне куйдык һәм без моңа ирештек тә. Яшьләребезнең күпчелеге югары һәм урта белемгә ия булдылар, фән казанышларын үзләштерделәр. Үсеш кайберәүләр өчен берьяклы гына өстенлек алды, холык үзенчәлеге туды, ата-ананы тыңламау, олыларны санга сукмау кебек гадәтләр эчне пошыра башлады.

Без педагогика дибез. Әмма аның ике тармактан торуын онытмаска кирәк. Монысы барыбызга да таныш. Ул баланы өйдә, бакчада, мәктәптә, җәмәгать урыннарында тәрбияләүне максат итеп куя. Бар халык педагогикасы. Монысы ата-бабадан, язылмаган кагыйдәләр аша телдән-телгә күчеп килгән педагогика. Бу безнең татар халкы өчен аеруча хас булган тәрбия чыганагы. Баланы яшьли хезмәт сөяргә, олыларны ихтирам итәргә, тәүфыйклы, ягъни әдәпле һәм культуралы булырга өйрәтү ул. Әйтергә кирәк, соңгы вакытларда безнең яшьләр менә шушы олылар тәрбиясеннән ераклаша баралар.

Олы бәйрәмегезне котлап әйткән теләкләремнең асылы шунда, хөрмәтле аналар, алда торган бурычларны тоеп, әлеге тәкъдимнәрне искә алып, чорыбызга лаеклы, белемле, тәрбияле балалар үстерегез. Моны заман таләп итә.

Мирза МӘХМҮТОВ,
академик.

Әгәр дә мин шагыйрь булсам, бу бәйрәмдә сөекле хатын-кызларыбызны ялкынлы шигырем белән тәбрик итәр идем. Бу шигырьдә мин күңелемдәге иң изге, иң тирән, иң нечкә хисләремне әйтеп бирер идем. Бу шигырьнең юлларын мин, асылташлардан муенса тезгән кебек, телебездәге иң эчкерсез, иң ягымлы, иң ялкынлы һәм иң матур сүзләрдән генә тезәр идем.

Мең-мең рәхмәт, чиксез ихтирам сөекле апа һәм сеңелләребезгә!

Гомәр БӘШИРОВ,
язучы.

Хөрмәтле редакция!

Сез миңа безнең сөйкемле, эшчән хатын-кызларыбызга 8 март уңае белән котлау сүзләре язарга мөрәҗәгать иткән идегез. Котлау җыйнак булсын, берничә җөмләдән артмасын, чөнки журнал битендә башка ир-атлар да уңган, гүзәл хатын-кызларыбызны тәбрикләргә ашкынып торалар, дигән идегез.

Зинһар, гафу итегез, мин котлау сүзләре язудан баш тартам. Сәбәбе — Сезнең миңе чикләвегез. Ничек инде ул нәфис, батыр хатын-кызларыбызны берничә җөмлә белән генә котлап булсын! Аларны тәбрикләп әйтәсе сүзләремнең яртысын гына язып Сезгә илтсәм дә, журналыгызда бүтән ир-атларга урын калмаячак. Бүтән ир-атларның котлавын сызып ташларга ризамы Сез! Әлбәттә риза түгел. Бәс, шулай булгач, өйдә миннән булсын яхшылык, бүтән ир-атлар котлап куансыннар, ә мин бөек, күркәм хатын-кызларыбызга багышланган иң матур сүзләремне күңелемнән генә кабатлармын.

Сәлам белән, Туфан МИҢНУЛЛИН

дуслар!

Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!



АЗАТ ХАТЫН 3
МАРТ
Иҗтимагый-политик һәм әдәби-нәфис журнал. 1979

© «Азат хатын» 1979 ел.

«Безгә һәр хезмәт иясенең, һәр хезмәт коллективының үз эшен яхшыртуы белән кызыксынуы кирәк... Безгә эшлекле, чын мәгънәсендә халык арасыннан күтәрелгән, миллионнарча кешеләрне кабызырга, рухландырырга сәләтле инициативалар кирәк. Артта калучыларсыз эшләү — әнә шуларның берсе. Безгә нәкъ әнә шундый башлангычларны таратырга кирәк».

Л. И. БРЕЖНЕВ

(КПСС Үзәк Комитетының ноябрь Пленумындагы чыгышыннан)



Мәрвәрҗиһан Җәләлиева цех начальнигы Илсөяр Сабирова янынннан шатлыклы хәбәр алып чыкты.

— Безнең коллектив тагын беренче урында,— диде ул.

Күлмәкләр һәм эчке киемнәр тегү берләшмәсенең 1 нче фабрикасында бу участок шулай айдан-айга гел җиңүчеләр сафында була.

Төшке ял вакытында ярыш йомгакларын иркенләп тикшерделәр, фикер алыштылар.

— Зинаиданың балалары янына кайчан барып кайтырбыз икән!— диде шунда группаның комсоргы Халидә Гыйлаҗева, җаен туры китереп.

— Бүләккә нәрсә яхшырак булыр икән!— дип Зоя Хохлова да сүзне куәтләп җибәрде.

Бурнашевская исә конкрет тәкъдим дә кертте:

— Хәзер язга таба барабыз, язгы киемнәр алыйк!

— Минемчә, Надя дөрес әйтә, аларга язгы әйберләр кирәктер,— диде тегүче Рәхимә Шәяхмәтова.

Халидә, Зоя, Надя — өчесе дә Рәхимәнең укучылары. Яшь кызларның нәниләр турында кайгыртып, беренче сүзне әйтүләренә остаз чиксез сөенде. Премия хәбәрен ишетү белән, «тегене алам», «моны алам», дип кабаланмыйлар, ә әнисез калган балаларны шатландырырга ашыгалар бит!

Зинаида Казеева да шушы ук бригадада эшләгән иде. Уйламаган җирдән авырып китеп, гүр иясе булды. Ике баласы ятим калды.

Мондый чакларда Рәхимәнең йөрәге кысылып-кысылып ала. Ул үзе дә әтиәнисез үсте шул. Еллары да нинди иде әле!! Авыр сугыш кешеләрне иңрәткән, халыкның үзәгенә үткән чак. «Барысы да фронт өчен!», «Барысы да Җиңү өчен!» дигән лозунглар һәркемнең йөрәгенә уелган еллар иде.

Үзенә никадәр генә авыр булмасын, Ватан-ана балаларын җиде юл чатында калдырмый. Рәхимәне дә Кама Тамагы районындагы балалар йортына озаттылар.

Балалар йорты Рәхимә өчен үзе бер дөнья, йөзләгән баланы кочагына алган, үзенә сыендырган зур гаилә — бик тә үзенчәлекле тормыш мәктәбе була. Укытучылар, тәрбиячеләр һәр баланың күңелен табарга тырышалар, ятимлек, бәхетсезлек турында сөйләшмиләр, нәрсә турында гына сүз чыкса да, ул килачәккә барып тоташа.

Үзеннән кечерәкләрнең төймәләрен тагу, сүтелгән, ертылган киемнәрен ямаштырып бирү Рәхимәнең яраткан шөгыленә әверелә. Бер үк вакытта кызларны, малайларны энә-җеп тотарга да өйрәтә ул. Аның янына түгәрәкләнеп балалар утыра, барысы да авызларын ачып, «укытучы»ның сүзен тыңлый, эшен күзәтә. Һәркөн шулай. Рәхимәнең җөйләре тәрбиячеләрне дә таңга калдыра. «Синә тегүче булырга кирәк», дип әйтергә дә онытмыйлар алар. Шулай итеп кызның күңеленә оеткы салына. Җиденче классны тәмамлаганда фикере инде ныгып та җитә. Балалар йортындагы беренче күнегүләр яшьлек хыялына әйләнә. Җиденче классны бетерүгә, Рәхимә Казанга килеп, фабрикага эшкә урнаша. Ә соңыннан, кичен укып, урта

БҮЛӘК

ОЧЕРК

мәктәпне тәмамлады, коммунист булды.

...Моннан берничә ел элек, профессиональ-техник училищены бетереп, яшь кенә бер кыз фабрикага эшкә килде. Тегүче таныклыгы булса да, осталыгы юк иде. Аны Рәхимәгә бирделәр. Бер карау белән сизеп алды остаз: кызның күзләрендә ниндидер бер моң бар. Хәсрәте-кайгысымы — нәрсәдер үз урынында түгел.

— Синең иң бәхетле көннәрең,— дип сүз башлады Рәхимә.— Хезмәт юлына аяк бастың. Хезмәт юлы — ул гомер юлы. Беренче адымнарың матур булса, тормышың да якты, гүзәл булыр... Үзем дә бик яшьли монда урнашкан идем. Серемне бүлешерлек дуслар, авыр чакларда киңәш сорардай апалар таптым. Хәзер инде мине бу фабрикадан аерып алырлык көч юк. Һәркемнең туган көнен билгеләп үтәбез. Менә тиздән сине дә беренче тапкыр хезмәт хакы алуың белән котларбыз.

Кызга сынап карап алды да:

— Синең бик бәхетле көннәрең,— дип кабатлады Рәхимә — тик, сеңлем,, нигәдер боек күренәсең. Әллә тегүче һөнәренә күңелең ятмыйммы!

— Юк, тегүчелеккә үзем кызыгып кердем, миңа ошый ул,— диде Надя Бурнашевская. Аннары ул күзләрен бер ноктага төбәп уйланып торды да:— Безнең семья бик ишле, без җиде кыз... Әни авырып тора. Апалар кияүгә чыкты, дүрт сеңлем белән әниемне карау минем өстә...

Рәхимә кызарып китте. Аны-моны абайламыйча артык төпченүе өчен уңайсызланды. Шулай да тиешле сүзен табып әйтте:

— Иң авыры инде артта калган дип исәплик. Менә хәзер үзең эшли башлыйсың, хезмәт хакы монда алай начар түгел. Кирәк чагында үзебез дә булышырбыз.

Надя Бурнашевскаяның гаилә хәлләре турында остаз цех начальнигы Илсөяр Сабировага, группа мастеры Мәрвәрҗиһан Җәләлиевага да сөйләде.

Сүз бер булды: кызга кулдан килгәнчә ярдәм итәргә. Иртән эшкә килү белән, Надядан һәммәсен-һәммәсен җентекләп сораша башлыйлар. Баштарак кыз сөйләргә бераз уңайсызланыбрак тора иде, аннары сеңелләренең нинди билге алуларын да, ничек шаяруларын да хезмәттәшләренә сөйли торган булып китте. Гаилә белән цех арасында күзгә күренмәс гаҗәеп бер күпер сызылды.

Бервакыт Рәхимә Шәяхмәтова Надядан:

— Бүген эштән туры өегезгә кайтасыңмы!— дип белеште.

— Кайтам,— диде кыз өзеп.— Анда бит мине көтеп торалар.

— Бер-ике сәгатьтән сезгә барып чыксак, ничек булыр икән! Әниегез, сеңелләрегез белән сөйләшеп, танышып алыр идек.

— Рәхим итегез, безнең ишек һәрвакыт ачык,— диде Надя шатланып.— Әни дә килгән кешене ярата. Кызын эшкә өйрәтүчене күрсә, бөтенләй эреп китәр.

Смена бетүгә Надя Бурнашевская өйләренә ашыкты, тегүчеләр исә җый-



Рифкат ЯКУПОВ фотосы

наулашып кибетләргә йөрергә киттеләр. Иң элек анага эре-эре чәчәкләр төшкән күлмәклек алдылар. Кызларны да бүләксез калдырмадылар. Кызыклы китаплар да эзләп таптылар. Чәй янына куярга конфет-мазар да булды...

Кунакларның һәркайсы ана белән кул биреп күреште. Кызларның кечерәкләрен күтәреп үк алдылар. Өйгә керделәр. Артык бай булмаса да, квартира чиста, пөхтә итеп җыештырылган иде.

Надя иң элек Рәхимә апасы белән таныштырды.

— Минем остазым шушы була инде, әни,—диде ул бераз кызара төшеп.

— Бусы группаның мастеры, Мәрвәрҗиһан Җәләлиева. Гомер буена фабрикада эшли.

— Сезнең янга урнашкач, кызымның да йөзе ачылып китте,—диде ана.— Үзегез дә бик ачыклар икән. Ничек соң, кызымны ачуланмыйсызмы, сүзегезне тыңлыймы?

— Ачулансак, өенә шулай җыелып килмәс идек. Бик тырыш кыз үстергәнсез,— дип Мәрвәрҗиһан анага рәхмәтен әйтте...

Менә шулай итеп тегүчеләр белән гаилә арасында дуслык башланды. Җае чыккан саен киләләр, кызларга я туфли, я күлмәк бүләк итәләр. Премия алган саен җыелып нәрсәдер алу матур бер гадәткә әйләнде. Туганнарча якын итеп йөрүләре, кайгыртулары бүләкләреннән дә кадерлерәк иде, әлбәттә.

Кечкенә кызлар да, авыру ана да күз алдында үзгәрделәр. Надяның үзен дә танырлык түгел, йөзендәге боеклык, язгы кояш нурлары астында эрегән боз сыман, юкка чыкты. Осталыгын арттырганнан-арттыра барды, икенче аенда ук нормасын үти башлады.

Ә остазның уйлары тагын да катлаулырак эшләр тирәсендә бөтерелә иде инде.

— Надя,— диде ул,— берүк мине дөрес аңлый күр. Әниеңне, сеңелләреңне карауның бик зур мәшәкать булуын да беләм. Тик, ничек кенә булмасын, үзеңнең киләчәгең турында кайгыртмый ярамый. Яшьлекнең узып киткәнен сизми дә калырсың, аны кире кайтарып булмый... Быел ук кичке мәктәпкә керергә кирәк. Кешеләр эшли-эшли техникумнар, институтлар тәмамлый әле. Хәзер бит укыйм дигән яшьләргә бөтен шартлар тудырылган.

Кыз җавап бирергә ашыкмады. Күзләрен тутырып остазына карап алды. Ул ни әйтергә дә аптыраган иде төсле.

— Җиңел булыр дип әйтмим,— диде Рәхимә апасы.— Әмма кыенлыкларны җиңсәң, куанычы да зуррак була. Каршылыксыз гына дөнья бармый ул. Мин сине бераз беләм инде, бер тотынсаң, кире чигенмисең син. Ә укырга кирәк, бик кирәк.

Надя кичке мәктәпкә керде. Вакыт азрак булган саен кеше җитезләнә дигән сүз хак икән. Барысына да өлгерде кыз. Берничә һөнәр үзләштерде. Унберенче классны да уңышлы тәмамлады, эшли-эшли югары белем алырга исәбе.

Хезмәтендә дә остаруы җитте: смена нормасын 140 ар процентка үтәүче алдынгыларның берсе ул хәзер. Рәхимә апасы бишьеллык планны өч ел ярымда үтәргә йөкләмә кабул иткән иде. Аның башлангычына беренче булып шәкерте Надежда кушылды.

Остазның түбәсе күккә тигәндәй булды. Ул өйрәткән кыз аның үзе белән тиңләшергә, хәтта узып китәргә җыена. Әмма бу — җиңелү түгел, бу — үзенчә бер җиңү. Әле беркөннәре генә Надежданың әнисе кызык сүз әйтте.

— Мин балаларыма тормыш бүләк иттем, ә сез безгә шатлык бүләк иттегез,— диде ул чын күңелдән.— Ә бит кешегә шатлыксыз яшәве бик авыр.

— Сез бик зурдан кубып сөйлисез,— диде Рәхимә апа каршы.

— Бер дә зурдан купмыйм, кадерлем, сез бит безнең тормышка яшәү сулышы өрдегез, минем башым күтәрелде, күзләрем ачылды, җиде кызым да — җиде кайгым түгел, җитмеш шатлыгым кебек... Миңа Надя сөйләгән иде: үлгән хезмәттәшегезнең балаларын ташламыйсыз икән. Идел кебек киң күңелле кешеләр сез.

— Минем үземә дә бик күп булыштылар шул, миңа да бүгенге көннәремне кешеләр бүләк итте,— диде Рәхимә.

Ул балалар йортындагы тәрбиячеләрен, укытучыларын, юлда очраган изге җаннарны берәм-берәм искә төшерде, җиде кыз табып үстергән ана елыйелый тыңлады аны.

Мидхәт МИНШИН.

ШАУЛАСЫННАР

Икмәк булса, җыры да була...
Л. И. БРЕЖНЕВ.

Ипташләр, Равия Мәҗитова 1925 елда туган. Аның 40 елга якын гомере Кукмара районының «Алга» колхозы кырларында уза. Шул еллар эчендә колхозда аннан башка бер агроном да, бер мелиоратор да, бер генә селекционер да булмады. Барысын да Равия апа алмаштырды. Эшли башлаган елларында гектардан 6—7 центнер уңыш биргән җирдән ул 20—25 центнер уңыш үстерүгә ирешә. Сынау өчен Равия апа «Москва-35» сортлы бодай чәчте һәм аның һәр гектарыннан 34 әр центнер уңыш җыеп алды. Барыгызның да күз алдында: ашлык тапшыру буенча план үтәми калганыбыз юк, икешәр план биргәнебезне дә беләсез. Колхозыбыз орлыкчылык буенча район базасына әверелде. Без әзерләгән үлән, печән орлыгын бик ераклардан соратып алдыралар. Үткән ел колхоз кассасына орлыкчылык буенча гына да 300 мең сум доход керде. Равия Абдулловнаның тырыш хезмәтен күреп, аңа Татарстанның атказанган агрономы исеме бирелгән икән, димәк, ул шуңа лаек... (Көчле кул чабулар).

(Колхозчыларның гомуми җыелышы беркетмәсеннән).

АГРОНОМ БУЛАМ

Сугыш беткән елны Равияне районга чакырдылар. Кыз төн утырып, эш планнарын карады, кирәк булса дип, чыгыш ясарга әзерләнде. Районга барып, җыелышның булмавын белгәч, аптырап калды. Туп-туры райкомга керергә куштылар. Кызны анда олылап каршыладылар, урын тәкъдим иттеләр.

— Шулай, сеңлем, — диделәр аннары, — колхозларга белемле кадрлар кирәк. Иң авыр чакларда көчеңне күрсәттең, белем кирәк сиңа. Без менә уйлаштык, киңәштек тә, сине укырга җибәрергә булдык. Синнән бик уңган председатель чыгачак. Әйдә, өч елга укырга кит.

Равия уйга калды. Кырларны, басуларны кемгә ышанып калдырасың! Бер ел булса бер хәл әле, көз уңыш алгач китеп, язгы чәчүгә әйләнеп тә кайтыр идең. Озаграк шул. Аннан соң күңелдә йөрткән хыяллар да бар бит. Бу тәҗрибәле агайлар белән бәлки шушы серне уртаклашырга кирәктер. Укырмын, агроном булырмын, дигән максаты да бар...

Аңа 16 яшь тулганда, сугыш башланды. Игеннәр ишелеп уңган иде, җыеп алулары гына шатлыклы булмады. Авылда яшүсмерләр һәм карт-корылар гына. Ил өстенә төшкән авырлыктан, колхоз өстенә килгән куркынычтан югалып калмас өчен каты куллы, сизгер күңелле бер хуҗа кирәк иде...

Менә шундый көннәрдә Равия Мәҗитованы «Яшел тау» колхозына чакырып алдылар да энтомолог итеп билгеләделәр. Бу сүзнең төп мәгънәсен кич әтисе аңлатып бирде. Корткыч бөҗәкләр белән көрәшүче, үсемлекләрнең саклаучысы һәм беренче ярдәмчесе дигән сүз була дип, үзенчә бик тирән мәгънә салып аңлатты Абдулла абый кызына. Үзе авылда яшелчә үстерүче, яшелчә орлыклары булдырып, тирә-күршегә өләшүче бердәнбер кеше буларак, кызының бик олы эшкә алынуын йөрәге белән тойды.

Җирне яратсын, икмәкне олыласын иде аның кызы. Шундый күркәм сыйфатлары булса, эшләве дә җиңелгәрәк килер. Бабайлардан калган дип, әллә инде үзе уйлап чыгарып, әтисе бер риваять тә сөйләп алды. Имеш, борын заманда бер карт тамак ялгаганда ялгыш кулыннан ипи валчыгын җиргә төшергән. Нишләргә, бу карт бик зур гөнаһлы булган бит инде. Уйлап-уйлап торган да, шул урынга бер кеше дә аяк басмаслык итеп, читән корып куйган, ди. Легенда шулай буыннардан-буыннарга күчә-күчә безнең көннәргә килеп җиткән. Равия дә әлеге изге карт турындагы риваятьне уллары Марат белән Рафикъка кечкенә чакларында ук сөйләде.

Икмәк һәм аны үстерүчеләр турында җырлар һәм хикәя-романнар иҗат ителә. Л. И. Брежнев үзенең «Чирәм җир» әсәрендә икмәк турында нинди матур итеп яза. Икмәксез тормыш, яшәү, алга барыш юк. Икмәк булса барысы да була, хәтта җыр да... Олы һәм мактаулы эш ул игенче булу, иген үстерү.

ТАМЫРЛАРЫ ТИРӘНДӘ

Җыелыштан соң гына чыктылар. Язгы чәчү тәмамланган көннәр. Эшләнгән эшкә йомгак ясадылар, эшләнәсенә планнар кордылар. Чөгендер басуларын карау көн тәртибенә басты. Тракторларны эшләтү өчен бер тракторчы җитми. Басуларга кертелергә тиешле гербицид бер генә көнгә соңга калса да яшь үсентеләр зарарланачак. Кәбестәне борча баса, самолет чакыртасы бар. Узган ел рогорны күбрәк сипкәннәр иде, быел гел карап кына эшләтергә туры килә. Иртәгәдән урып-җыю машиналарына соңгы күзәтү ясарга. Равия Абдулловна, соң булса да, югары очтан урап кайтырга булды. Рәсүлнең малае армиядән кайткан, дигәннәр иде. Тракторга утырмасмы икән! Олы өметләр баглаган иде аңа Равия ул чакта. Колхозның экономикасы турында да, киләчәктә һәр механизаторның хезмәт хакы 150—200 сум булачагы, колхозга яңа техника кайтачагы турында да бик бирелеп сөйләгән иде. Әмма егет колхозда калмады. Тик әнисе генә Равиягә: «Кеше балаларын котыртып йөрмә, үзең-

ОРДЕННАР

Розалия газета битләрендә әледән-әле чыга торган ак халатлы савымчыларның, комбинезонлы игенчеләрнең елмаеп төшкән фотоларын, алар турында язылган мәкаләләрне укый да үз алдына максат куя иде: мәктәпне генә тәмамлыйм, тырышып колхозда эшли башлыйм. Әнә, үзләрендәге терлекче Гыйззәтуллинаның да түшен Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бизи. Әлеге үрнәк кызның омтылышларына көч бирде. Башта ул, бригадир нинди эшкә кушса, шунда барды.

Нәкъ шул елларда Норлат янында шикәр заводы салына башлады. Аны чимал белән тәэмин итү өчен районның Яңа Иглай авылында да шикәр чөгендере игәргә тотындылар. Розалияне чөгендер звеносына чакырдылар. Башта кыенрак булды. Беренче елны гектардан нибары 25—30 центнер гына уңыш алды звено. Розалиягә чөгендерне лом белән вата-вата казып алырга туры килде. Әмма кызның тырышлыгы бушка китмәде, башка участокларга караганда уңышны икеләтә күбрәк җыеп алды һәм район күләмендәге ярышта беренче урынга чыкты.

Ләкин Розалия ирешелгәннәр белән генә чикләнергә теләмәде. Район китапханәсенә барып, чөгендер игәргә өйрәтүче китаплар, брошюралар җыеп кайтты, шуларда әйтелгәннәрне практикада сынау өчен үзенең яшелчә бакчасында берничә түтәл чөгендер утыртып карады. Бу культураны яхшылап эшкәртү, ашлау буенча шактый тәҗрибә туплады. Аннары хезмәттәшләре Гайнуллина, Саттаровалар белән үзара ярыш ачтылар. Көндәшләре дә уңганнардан иде шул, үзен берничә мәртәбә узып киткәләгән чаклары да булды. Ләкин соңыннан беренчелекне барыбер бирмәде.

ИГЕН КЫРЛАРЫ

некеләр дә үсеп килә, кем булырлар икән!»— дип әйтеп калды.

Әле моннан ике-өч ел үткәннәрне искә алгач та Равиягә рәхәт тә, кыен да булып китте. Төн үзе җылы, үзе дымлы. Игеннәр шытар өчен иң яхшы чак. Өченче участокта да икенче классны орлык чәчкәнгә иртәгә җиде көн була. Тишелеше әйбәт булачак. Күңел ышана. Ышаныч туганчы гына күпме йокысыз төннәр үткәрергә туры килә.

Кыш башлангач, әгәр агроном хезмәте турында аз белсәң, аларга бер эш тә калмаган төсле тоела. Ләкин, Равия Абдулловна әйтүенә карагaндa, бу чор урак өстеннән бер дә ким түгел икән. Кышын лабораторияләрдә киләсе ел уңышы сынау уза. Кайсы агрономда юк инде ул беренче классны гына орлык чәчү теләге. «Алга» колхозы хәзер өченче классны орлык чәчми башлады. Күп тә үтмәс, беренче класслыны гына чәчә башларлар.

Равия, балаларын уятмаска теләп, акрын гына үтәргә уйлаган иде, зур улы Марат имтиханнарга әзерләнеп утыра икән. Әнисен күрү белән чәйнекне электрга тоташтырды. Китапларын бер якка куеп, өй яңалыкларын сөйләп алды. Энесе Рафикъ өчен дә тулысынча җаваплы кеше бит әле ул. Әнисенең күзләрендә ару күрсә дә, күңеле тыныч. Марат иң зур серен ачарга булды. «Әни, мин колхозда калам, мәктәптә алган һөнәрем бар, шофер булам». Алай гына булмый икән әле. «Син колхоз механизаторы икән, теләсә кайчан, теләсә нинди техника белән идарә итә белергә тиеш. Шуның өчен СПТУда укып кайт башта», — диде әнисе.

Марат хәзер әтисе белән бергә колхозда шофер булып эшли. Энесе инде СПТУда укый. Ул да колхозга механизатор булып кайтачак. Равиянең хыяллары тормышка ашты. Соңгы ике елда гына да армиядән 18 механизатор егет кайтты, теләсә нинди машинаны йөгәнләрлекләр. Колхоз механизаторы агроном хезмәтен дә белергә тиеш икән. Шуңа күрә кышка керү белән алар өчен агротехник укулар башлана. Равия апалары лекция укый, җир серләрен өйрәтә. Егетләр уңган, колхозның кызлары гына Кукмарага эшкә китәләр китүен, колхозның көннән-көн алга баруын ишетсәләр, алар да уйланырлар әле.

Теге чакта малаен читкә — шәһәргә җибәргән апа да бик үкенә, ди. Читтә бик яхшы булса, Равия үз малайларын җибәрер иде. Аларның тамырлары җирдә, шуңа да мактаулы алар, ди икән.

ЙӨРӘК ҖЫЛЫСЫН КУШЫП

1978 ел игенчеләр елъязмасында авыр ел булып язылды. Язгы яңгырлар озак дәвам итте, игеннәр сабакка үстеләр. Уртача 25—30 центнер уңыш җыеларга тиеш иде. Тик урып-җыю озакка сузылды. Механизаторлар, комбайнчылар кара көзгә кадәр басуда ашлык суктырдылар. «Саратов-36» сорты уңышны күп бирә, дип шуны чәчкәннәр иде, елы килешмәде. «Москва-35»не юештә бераз сугарырга була икән булуын, тик орлыгы зарарлана. Киләсе елга нинди орлык чәчәргә! Һава торышына нинди сорт килешер! Агроном уйлана, идарә членнары белән киңәшә, картлар белән сөйләшә. Игенче ялгышырга да мөмкин, әлбәттә. Шуңа күрә дә Равия, нинди орлык чәчсә дә, җиргә нинди генә ашлама сипсә дә, беренче чиратта сынау үткәреп карый. Сынау нәтиҗәләренең дөреслегенә тулысынча ышангач, киң мәйданга чыга. Ә сынауларны бик күп үткәрергә туры килде аңа. Колхоз җиренең күп мәйданы шактый озак җансыз ятты. Чөнки таулыклар, калкулыклардан тора. Арыш, бодай чәчү турында уйларга да мөмкин түгел. Тик яткан җирләргә люцерна чәчкәннәр иде, ишелеп печән уңды. Орлык сатып алу печән белән бер бәягә төшә икән. Һәм Равия Абдулловна люцерна орлыгын үзе әзерли башлады. Үзләренә дә җитте, тирә-күрше колхозларга да өлеш чыкты. Кукмара районының «Алга» колхозы турында еракларда ишетеп алдылар. «Безгә дә бирмәссезме икән!» — шундый сораулар күп килә башлады. Ерак дип тормыйча, Украинадан да, Мәскәү, Ленинградтан да килделәр орлык алырга.

Колхозда зур җыелышка алдан әзерләнсәләр дә, көне-сәгате җиткәч кенә белде Равия. Бухгалтерия кызларыннан берәү: «Равия апа, матур киенеп кил, сиңа багышланган кичә була»,— диде дә, үзе дә аптырап калды. Ничек шулай гел матур икән Равия апалары!..

Райком кешеләре дә, районның авыл хуҗалыгы идарәсенең баш агрономы Райнур Рәхимуллин да мактау сүзләрен кызганмадылар. Үзенә сүз биргәч кенә каушап калды Равия. Ярый әле, авылдашларына рәхмәт, дип әйтә алды. Арттан: «Гаптелфәткә дә рәхмәт әйт»,— дип кычкырдылар. «Әйе, картыма да рәхмәт. Ул беренче ярдәмчем булмаса, атказана алмас идем». Соңрак Равия Мәҗитованы котларга колхозның элекке председателе, пенсионер Әсрар ага да килде. «Син, килен, мине гаеп итмә инде, уллар тудырыр алдыннан мин сине ялга җибәрми идем, медпунктка менеп киткәч, акушеркага тагын бер генә атнага җибәрми тор, дип әйттерәм. Бер генә атналар өчәр-дүртәр тапкыр кабатлана иде. Улларың тугач та ике-өч ай узу белән чакыртып алдым. Синсез булдырып булмый иде. Игеннәргә йөрәк җылыңны җәлләмәдең...»

Бу сүзләрдә олы хаклык бар. Равия апа үзе дә «Хатын-кыз агроном булсын, игеннәргә йөрәк җылысын, ана назларын кушсын»,— ди.

Фәния ХУҖИӘХМӘТОВА.

КАВАЛЕРЫ

Авылга кайчандыр калага киткән егет кунакка кайткан иде. Әлеге шул сөйкемле егет тәки яулады кызның күңелен. Гөрләтеп туй ясадылар. Гаилә түгәрәкләнә барды, балалар үсеп аякка баса башладылар, әмма йорт мәшәкатьләре уңган игенченең эшенә комачаулый алмады, сынатырга, якташларыннан калышырга теләмәде ул.

Еллар бер-бер артлы уза торды. Тормыш җиңеләя, эш уңайлана барды. Элек плантациягә җәяү йөриләр иде, хәзер инде аларны машина илтә, машина алып кайта. Кул көчләрен дә машиналар алыштырды. Колхоз берничә хуҗалыкны берләштергән «Рассвет» совхозы булып оешты, яңа йортлар калыкты, таш клуб салынды, китапханә баеды. Тырышып эшлә, иркенләп ял ит, барлык мөмкинлекләр бар инде хәзер.

Розалия Вәлитова җыелышларда әйтәсе фикерләрен оялып кына, кызарып кына түгел, чатлатып әйтә хәзер. Ул район һәм авыл Советына берничә тапкыр депутат булып сайланды. «Совхозыбыз соңгы елларда чөгендер игү буенча республика күләмендә алдынгылардан саналып, һәр гектардан 370—400 центнер уңыш алып килә икән, киләсе елларда да без моңа ирешергә тиеш», — диде ул урып-җыю алдыннан гомуми җыелышта ясаган чыгышында. Совхоз күләмендә чөгендер игү остасы исеме алган иптәш Вәлитова бу көнне бәйрәмнәрдә генә кия торган костюмын кигән, аның түшендә тырыш хезмәте өчен бирелгән Ленин ордены һәм Хезмәт Кызыл Байрагы ордены балкый иде.

Халык орденнар кавалерының җитди чакыруына җавап итеп гөрләтеп кул чапты, ә соңыннан аңа эш белән җавап бирде — совхоз дәүләткә чөгендер сату планын намус белән үтәде.

Таһир ГОБӘЙДУЛЛИН.
Октябрь районы,
Яңа Иглай авылы.

Күптән түгел миңа Голландиядә булырга туры килде. Беркөнне Амстердамның матур каналларын, күперләрен карап йөргәндә Анна Франк музее янына килеп чыктым...

Икенче бөтендөнья сугышы вакытында Амстердам шәһәрендә ике ел буе бер семья яшеренеп чарлакта яши. Гитлерчылар аларны табалар, ата-аналарын Освенцимга, ике кыз баланы башка концлагерьларга озаталар. Үлем җәзасына тартылачакларын белеп тә, бу семьяны качырып тоткан дуслары тентүдән соң чарлакта кызыл тышлы бер дәфтәр табалар. Бу — 13 яшьлек Аннаның көндәлеге була. Немецлар ул дәфтәр белән кызыксынмаганнар һәм анда үзләренә каршы нинди гаепләү сүзләре булуын белми калганнар. 1945 елда әлеге язмалар «Анна Франк көндәлеге» дигән исем белән басылып чыга, күп тә үтми, язмалар буенча кино төшерелә.

ГАЕПЛӘҮ ДОКУМЕНТЛАРЫ

Күптән түгел Англиядә чыккан бер брошюрада «Анна Франк көндәлеге» — ул уйлап чыгарылган нәрсә, концлагерьлар исә ял йортлары булган, крематорийларда кешеләр яндыру һич тә булмаган» , — дип язганнар.

Сугышны үзе күргән, төрмә һәм концлагерьларда интеккән кешеләр үткәннәрне онытмыйлар. «Литературная газета»да (1977 ел, 27 июль) хәбәрче В. Вавиловның Аннаның атасы Отто Франк белән әңгәмәсе урнаштырылган иде. «Бүгенге көн кешеләре үткәннең дәһшәтле сабакларын онытмаска, фашизмның яңадан калкып чыгуына юл куймас өчен көрәшергә тиешләр,— дигән Отто Франк.— Мин сугышның нәрсә икәнен бик яхшы беләм. 1945 елның 16 гыйнварендә рус солдатлары Освенцим лагерен азат иттеләр һәм без, исән каласыбызга ышана да алмаган кешеләр, аларны кочаклап еладык. Ә миллионлаган башка гаепсез кешеләр белән бергә минем хатыным, кызларым Анна һәм Марго гитлерчыларның үлем лагеренда һәлак булдылар».

Анна Франк көндәлек язган йортта хәзер музей урнашкан. Анда Аннаның 54 илдә басылып чыккан көндәлеге куелган. Аерым бер шкафта аның рус, украин, грузин, казах, төркмән телләрендә чыккан көндәлеге саклана.

Бу экспонатлар һәркемне дулкынландыра, ул кечкенә һәм гади музейга халыкның өзлексез агылып торуы бигрәк тә зур тәэсир калдыра. Килүчеләрнең күбесе яшьләр. Алар һәр нәрсәне зур игътибар белән карыйлар, сөйләгәннәрне бирелеп тыңлыйлар, бөтенесен дә үзләре аңларга омтылалар. Һәртөрле газета уйдырмалары аларны канәгатьләндерми, күрәсең. Музейга килгән кешеләрнең фикерләре язылган дәфтәрне укыгач, Франция, Мексика, АКШ, Англия, Бразилия, Советлар Союзы һәм башка илләрдән килгән яшьләрнең тынычлык теләүләре бигрәк тә ачык күренә.

Анна Франк белән бер үк вакытта фашистлар басып алган Литва шәһәре Вильнюста икенче бер кыз, 14 яшьлек Мария Рольникайте да көндәлек алып барган. Ул да үзенең күргәннәре, уйлары, кичерешләре турында язган

Вильнюста да фашистлар яһүдләр өчен аерым бер тәртип кертәләр. Шәһәрнең борынгы матур урамнарын чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алалар. Һәрьяклап бикләнгән шул районда яһүдләр геттосы булдырыла.

Кешеләрне ачлык белән газаплау, колларча эшләтү анда гадәти бер хәл була. Ә аннан коточкыч нәрсәләр башлана. Балаларны ата-аналарыннан, хатыннарны ирләреннән аералар, Вильнюс тирәсендәге Понеряй дигән җирдә өледәнәле мылтык аткан тавышлар яңгырый. Үлеп бетмәс борын җиргә күмелгән кешеләрнең зур каберлеге үсә бара... Йөз мең кеше...

Анна Франк өеннән чыкмыйча, яшеренеп яши. Шуңа күрә аның көндәлегендә үзенең кичерешләре, әрнүләре күбрәк, яшьләй өлгергән баланың философик уйланулары бар. Мария Рольникайтенең көндәлеге вакыйгаларга бай. Монда бик күп кешеләрнең портретлары бирелгән. XX гасыр варварлары тарафыннан урта гасырдагы исем белән «гетто» дип аталган «үлеләр утравын» Маша ачык итеп сурәтли алган. Шул «үлеләр утравы»на Маша кайбер китапларын, дәфтәр, көндәлекләрен алып кергән һәм шунда күргәннәрен терки барган.

1943 елда Мария анасын, туганнарын югалта. Аннары аның үзен дә концлагерьга озаталар. Анда ул цемент капчыкларының ертылган кәгазьләренә көндәлек яза, алар булмаганда «күңеленә» яза башлый. Сүнеп баручы кыз концлагерь сәкесендә җөмләләр төзи, аларны ятлый.

Киләчәк буыннарга бу хәлләр сабак булсын өчен ул әлеге тәмуг, кешеләр сыйфатын югалткан фашистлар турындагы уйларын, сүзләрен саклап калырга һәм соңыннан аларны кешеләргә сөйләргә теләгән. Куллары белән кол хезмәтен үтәсә дә, җаны буйсынмаган. 14 яшьлек кыз пионер галстугын атасының киеме эченә тегә, тамга куйган күлмәген салып, туган көнендә икенче күлмәк кия, беренче май бәйрәме көнендә үзе язган шигырьләрен сөйли, иптәшләре белән бергә яшеренеп үзе язган җырны җырлый. Ә бит мондый эшләр өчен үлем җәзасы биргәннәр. Аның көндәлеге — XX гасырдагы иң авыр чорның кан белән язылган тарихы. Бу көндәлек — кеше хәсрәте һәм аның ныклыгы, трагедиясе һәм батырлыгы турында сөйләүче һәм, ниһаять, фашизмны гаепләүче документ. Мария Рольникайтенең көндәлеге «Мин сөйләп бирергә тиеш» дигән исем белән сугыштан соң басылып чыкты. Хәзер ул 18 телдә дөньяга таралган.

Әлеге әсәрне укыгач, мин озак вакытлар шуның тәэсирендә яшәдем.

...Дубулты. Язучыларның иҗат йорты. Өстәл артында без өчәү: Ленинград язучысы Михаил Семенович Панич һәм миннән башка тагын бер хатын. Панич аңа һаман «Машенька» дип кенә эндәшә. «Сез күргәннәрне сөйләп бетерерлек түгел инде», — ди ул беркөнне сүз арасында.

Мария Григорьевна үзенең ГДРга баруы турында сөйли һәм көлемсерәп: «Минем иң яхшы дусларым немецлар...» — дип куя.

Маша... Мария... Мин нидер сизенәм. Улмы әллә?

— Сез Мария Рольникайте түгелме? Безнең илнең Анна Франкы? Шулай бит?

— Әйе.

Ул миңа гаҗәпсенеп карый.

Мин аңа фашизмга каршы көрәшкә катнашкан язучыларның иҗаты белән кызыксынуым турында сөйлим. Аны күптән күрәсем килгәнне әйтәм. Әмма көндәлеге турында, оккупация еллары турында сорарга кыймыйм. Кешенең йөрәк ярасына кагылырмын дип куркам.

Ул бүген «Юрмала» дигән ял йортына очрашуга җыена. Мин дә аның белән барырга булдым, һәммәсен дә шунда ишетермен дип уйладым. Һәм шулай булып чыкты да.

Мария белән без бер ай бергә булдык. Дуслаштык. Минем өстәлемдә аның фоторәсеме. Ул моңсу гына елмаеп миңа карап тора. Китабының алдагы битендә ул: «Сиңа чын күңелдән бәхет, якты көннәр телим», — дип язган.

Фашизмга каршы көрәштә, икенче бөтендөнья сугышында катнашкан кешеләрнең әсәрләре гаять зур тәрбияви әһәмияткә ия, алар фашизмны гаепләү документы. 13-14 яшьлек Анна Франк һәм Мария Рольникайтенең язмалары да шундыйлар.

Миләүшә МАННУРОВА,
филология фәннәре кандидаты.

Әмирхан Еникига 70 яшь

СИРӘК ТАЛАНТЛАРНЫҢ БЕРСЕ



Әмирхан Еники турында сүз әйтү, бер үк вакытта читен дә, рәхәт тә. Читен, чөнки ул бик катлаулы, үтә дә нечкә күңелле художник. Әйтә белмичә әйтсәң, тота белмичә кулдан төшереп ваткан хрусталь ваза кебек, аның иҗатын чәлпәрәмә китерүең дә мөмкин. Рәхәт, чөнки аның иҗаты уйланырлык азык, күңелгә шатлык, колакка музыкаль аһәң бирә.

Менә шул кешегә, гел безнең арада булып, гел безнең кайгы-мәшәкатьләребезне уртаклашып, ләкин бер вакытта да, беркемгә карата да кесәсендә таш йөртми торган киң күңелле Әмирхан Еникигә 70 яшь тулды. Бу җитмеш елның илле елын ул әдәбиятка, әдәбият аркылы халыкка хезмәткә багышлады.

Яшь, зифа буйлы, кара чәчле, мөлаем егет, ул әдәбиятка ничектер кыяр-кыймасрак килеп керде һәм хәзергә хәтле, яше 70 кә җитеп, башы пеләшләнә башлагач та, уннарча повесть һәм бик күп талантлы хикәяләр авторы булгач та, безнең барыбызның да, иң әһәмиятлесе, киң катлау укучыларның ихлас мәхәббәтен казанганнан соң да шулай кыяр-кыймас кына барган кебек. Аның бу тыйнаклыгы үзенең көчен белмәгәнлектән түгел, юк, ул үзенең әфсенле көчен бик яхшы белә, аның бу тыйнаклыгы халык алдындагы бурычын тирәнтен аңлавыннан. Юк, әдәбият уйнар өчен түгел, әдәбият дан казану, акча эшләү мәйданы да түгел, әдәбият — энә белән кое казу, әдәбият — кеше күңелен тәрбияләү, әдәбият кешеләрне яхшы булырга, көннән-көн яхшырак була баруга этәрү коралы. Без менә шул бөек бурычны үтибезме? Барыбыз да бертигез үтибезме? Әмирханның тыйнаклыгы, минемчә, әнә шул сораулардан килеп туадыр кебек.

Терлек азыгына кытлык кичерүче колхозда терлекләрне кышын ничек исән-сау кышлату проблемасы («Рәхмәт, иптәшләр»), принципиальлекне югалткан партия җитәкчесенең әкренләп-әкренләп ничек түбәнгә тәгәри баруы һәм, ахырдан, җитәкчелектән бөтенләй төшеп калуы («Саз чәчәге»), яңа тип мещанлыкның үрмәкүч авына вак җанлы кешеләрнең ничек эләгүләре («Рәшә»), четерекле хәл-әхвәлләрдә кешенең, вөҗданын сатмыйча, ничек үзен саклап калуы («Вөҗдан»), икенче эшелонда гына булса да фронтның фронт икәнлеген сиздерүче «Без дә фронтта булдык» повесты һәм кеше җанының барлык тирбәлешләрен оста тасвирлаган, күңелне җыр кебек иркәләүче мәхәббәт повестьлары («Йөрәк сере», «Гөләндәм туташ хатирәләре»), боларның барысы янына тагын бик күп һәм Әмирханча зәвык белән язылган хикәяләрен китереп кушыгыз. О, кыяр-кыймас кына эшләгән кебек күренсә дә безнең Әмирханыбыз кочакны зурдан җәйгән икән!

Исемнәре аталган бу әсәрләрнең һәм кәгазьгә ашыгыч төшкән әлеге язмаларда исемнәре аталмаган әсәрләрнең бөтенесе өчен уртак бер сыйфат, гомумән, Әмирхан Еники иҗаты өчен иң күренекле сыйфат: ул да булса аларда, бөтенесендә, әлбәттә, төрлесендә төрле дәрәҗәдә, кеше җанының хәрәкәткә килүе. Ясалма конструкцияләргә чуар бизәкле какшау бина корудан ерак тора Әмирхан. Аның әсәрләрендә — бөтенесендә дә — җанлы кешеләр, газаплана һәм шатлык кичерә белә торган кешеләр яши! Әмирханның укучыны сихерли ала торган көче нәкъ әнә шунда.

Әмирханны үзенчәлекле художник итеп таныткан хосусиятләрнең тагын берсе — аның теле. Аның хикәяләрен, повестьларын укыганда телебезнең нинди көч-көдрәткә ия булганлыгын янә һәм янә бер кат төшенәсең. Логик эзлеклелек, сүз асты дөньясының тигез һәм тыныч агышы, нәкъ үз урыннарына утырган сүзләрнең, берсе икенчесеннән көч алып, музыкаль аһәңлелек белән җырлап торулары — боларны һәм әйтәм дигәндә телгә килмәгән башка күркәм якларны, беренче нәүбәттә, нәкъ менә Әмирхан иҗатыннан табабыз.

«Табабыз» — урынлы әйтелмәде. Аларны эзләргә кирәк түгел, алар әсәрнең тукымасында, алар — тасвирлана торган хәл-әхвәлләрнең мускулы, эчке пружинасы буларак, укучыны шундук эләктереп алалар һәм алып китәләр. Бу тасвирның әфсененә бер эләктеңме, ычкынырмын димә. Ул сине тирбәтеп һәм моңландырып, уйланырга һәм тормыш, көнкүреш картиналарына үз күзең белән карарга мәҗбүр итеп, алып бара, алып бара...

Әлләни зурны дәгъва итми торган менә бер өзек. «Йөрәк сере» повестыннан. Авторның лирик чигенеше. Дөресен әйткәндә, күп чигенергә урын да калмаган монда, әсәргә соңгы ноктаны кую алдыннан. Моннан бер ел элек Кавказ санаторийларының берсендә автор Зөһрә исемле сөйкемле бер ханымны очраткан. Танышканнар, йөргәннәр, бер-берсен яратышып өлгергәннәр, ханым авторга үзенең гыйбрәтле тарихын сөйләгән... Һәм инде аерылышканнар. Бер елдан соң автор шушы ук санаторийга тагы килеп төшә. Бөтенесе үз урынында — диңгез дә, таулар да, парк-бакчалар да. Тик ул гына, Зөһрә ханым гына юк... Ә автор өчен, гүяки, ул булмагач, бер нәрсә дә юк...

«Мин аны оныта алмыйм. Мин аның үзен дә, тавышын да оныта алмыйм. Күптән сагынып көткән көй булып очрады ул миңа... Очрады, шушы тын юлларны минем белән бергә таптады, көлде-җырлады, гыйбрәтле үткәнен сөйләде, аннары вакыты җиткәч, ак, кызыл чәчәкләр бәйләмен күкрәгенә кысып, миңа кулын изәп китте дә барды. Үз дөньясына, үз тормышына, үз бәхетенә!.. Гомергә, мәңгегә!»

Өзек-өзек ташланган соңгы җөмләләргә игътибар итегез. Моңлы бер симфониянең соңгы аккордларымыни! Җыр бар, моң бар, югалту бар, ләкин ачыну, өзгәләнү генә юк. Тик киткән кешегә, юл кешесенә ихлас күңелдән хәер-дога теләү генә бар...

Еллар, ун еллар узар, филологлар Әмирхан Еникинең телен, үзенчәлекле стилен өйрәнеп, монографияләр, гыйльми хезмәтләр язарлар, тик хәзергә — ай-һай ла! — безнең генә кулыбыз җитми.

Кыскасы, безнең Әмирханыбыз, безнең нечкә һәм сизгер күңелле, коеп куйган художнигыбыз, Әмирхан Еникиебыз бар, ул безнең арада, безнең белән иҗат итеп, бергә шатланып, бергә борчылып, дөньяга һәм кешеләргә бәхет-сәгадәт теләп яши. Аның бәйрәме безнең дә бәйрәм!

Фатих ХӨСНИ.



Туй итә Казан

Сара САДЫЙКОВА музыкасы

Сибгат ХӘКИМ сүзләре

2. Киләчәк бөек эшләргә
Үзен багышлый яшьлек,
Ант итә ерак чорларга
Узып барышлый яшьлек.

3. Гөр килеп туй итә яшьлек,
Үзе башкода Казан.
Тасмалар белән бизәлеп
Кая ашкына Казан?
Туй итә, бөек елларның
Каршына чаба Казан!





ҖЫР ТУГАНДА



Шагыйрь өендә телефон чылтырый. Трубкада:

— Сибгат! Булды! — дигән шатлыклы сүзләр.

— Ә-ә, Сара апа, синме. Булдымыни?!

— Булуын булды, тик миндә бит хәзер телефон юк, яңа квартирага күчендем. Уйнап күрсәтә алмыйм. Өегезгә барыйммы, пианино бармы сездә?

— Бар да бит, көйләнмәгән ул...

Алар композитор өендә очрашалар. Анда да яңа көйне тыңлау тиз генә булмый әле. Башта Сара ханым чәй табыны әзерли, Сибгат Хәкимне кыстый-кыстый сыйлаган була. Җыр хакында сөйләшүне бераз кичектереп торуның үз сере бар икән: көй яңгырашына җайлап композитор шигырьнең кайбер сүзләрен үзгәрткәләгән.

Бәхәс куера. Алар кайчак шактый ук кызышып, үпкәләшеп аерылышалар.

— Уйла әле, Сибгат! Нәкъ шул мин әйткән сүзләр булсын, димим, үзең тап, башкасын.

— Ярый-ый.

Ишетелер-ишетелмәс кенә әйтелгән шул сүз, җыр сәнгатенә бирелгән вәгъдә буларак, шагыйрьнең бөтен тынычлыгын ала. Көйгә ятышлы, строфа агышына кулай бер сүз, лирик образны тулыландырырдай яңа бер деталь эзләп атналар үтә. Инде табылды дигәч тә, композитор белән шагыйрьнең очрашуы тоткарлана. Берсе — гастрольдә, икенчесен авылдагы шигырь сөючеләр чакырып алган.

Әмма иҗат процессы тукталмый. Уйлану, эзләнү, җырның беренче вариантына яңа бизәкләр өстәү дәвам итә. Композитор белән шагыйрь табышларын бер-берсенә хат аша җиткереп торалар. Яңалык уңышлы дип табылса, хатлар хуплау сүзе белән тула. Композитор: «...Сибгат, синең шигырьгә көй тиз язылa!»—дип шагыйрьне шатландырырга ашыга. Шунда ук кайбер юлларның музыка кысасына сыймавын аңлата. Яңа үзгәрешләр яңа эзләнүләр, баш ватулар таләп итә.

«Хөрмәтле Сара ханым! Моңа хәтле мин Сезне җырчы, композитор, дип кенә белә идем. Сез әле тәнкыйтьче дә икәнсез. Кайвакыт, билгеле, арттырып та җибәрәсез. Кайвакыт урынлы. «Туй итә Казан» хәзер җыр булып ятты... Сезнең тәнкыйтьнең файдасы тиде, рәхмәт... Бу — лирик әйбер. Ритмы әйбәт, темпы әйбәт. Бик биетмәсәгез иде!..»

«Чәчәкләр җыям болында» җырын язганда да иҗади бәхәс шактыйга бара. Ниһаять, композитор шагыйрьнең катгый күрсәтмәсен ала.

«...көй шәп чыкты дигәнгә ышанам,— дип яза Сибгат Хәким.— Синең зәвык, таләпчәнлек ышандыра мине. Җыр ак, якты, лирик тонда. Ләкин «шутка» дигәнең бераз куркытты... Сүзләрдә драматизм көчлерәк, халыкта шулай бит ул.

Мин башка бер сүзне дә үзгәртмим!..»

Сара ханым, шагыйрьнең үтенечләрен дә, таләпләрен дә истә тотып пианино янына утыра, көйгә соңгы бизәкләрне салып чыга. Җыр әзер. Артистларга тәкъдим итеп, ничегрәк башкарырга кирәклеген өйрәтәсең дә, тыңлаучылар хөкеменә тапшырасың.

Халкыбызның яраткан композиторы, Татарстанның халык артисткасы Сара Садыйкова белән күренекле шагыйрь Горький исемендәге дәүләт һәм Тукай исемендәге премияләр лауреаты Сибгат Хәким арасындагы алтмышынчы елларда башланган иҗади дуслык нәтиҗәсендә дистәләгән матур әсәрләр туды. Бу гаҗәеп кыен, искиткеч ләззәтле иҗат кайчак җанны тәмам сыгып бетерә. Җитте, бүтән бу эшкә алынмыйм, дигән көнгә төшәсең. Тик... Шагыйрь күңеле җырсыз була аламыни? Сара ханым өенә хат китә. «...Син кайтуга менә тагын бер шигырь салам әле. Язылыр кебек, көй сорый кебек...»

Озак көттерми, шагыйрь өендә телефон чылтырый: «Сибгат, булды! Кил, тыңлап кара!..»

Яңа бәхәсләргә, эзләнүләргә, табышларга җирлек әзер...

Кояш ТИМБИКОВА.




Чәчәкләр җыям


2. Һәр караш минем йөрәкне
Көйдереп үтте төсле,
Сүзсез көйдергән карашлар
Ник болай үкенечле?

3. Җыелып бергә чәчәкләр
Килгәннәр күк яшьлектән.
Карыйлар күзгә, ә минем
Күзләремдә яшь кипкән.

4. Сорыйлар кебек чәчәкләр:
Я, әйт, нинди уең бар?
Уйлардан уелып калды
Йөрәгемдә уемнар.

Уртача тизлектә






Сусау


2. Ник болай сагышлы иттең
Бу кадәр мине соң син?
Аерылып бер көн дә узмый
Яңадан сиңа сусыйм.

Бу нинди гомерем буена
Бетмәгән сусау икән?
Үлгәндә башым очында
Су салып торсаң икән.

Хис белән








Рөстәм МӨХӘММӘТҖАНОВ фотолары.

Самат ШАКИР

ГАЛИМӘ ШӨГЕРОВА



Телевизор экранында — Испания башкаласы Мадридның спорт мәйданы. Миллионнарның карашы бүген аңа төбәлгән. Галимәнең әнисе Нәҗибә, әтисе Әхмәтгәрәй, әбисе Мәфтуха, энесе Рәшит тә телевизор алдында. Диктор аренага Галимә Шөгерованың чыгачагын әйтте.

Галимә тасма белән нәфис фигуралар ясый башлады. Ана дулкынлануыннан урынында утыра алмый, сикерә дә тора, сикерә дә тора. Ниһаять, ярышның нәтиҗәсе турында судьялар үз фикерләрен әйтәләр. Диктор:

— Галимә Шөгерова, иң күп балл җыйнап, дөнья чемпионы Ирина Дерюгинаны узып китте һәм беренче урынны яулады, — дип белдерә. — Европа чемпионы дигән мактаулы исемгә лаек булды!

Нәҗибә ханымның күзләрендә шатлык яшьләре мөлдерәп. Ул пьедесталда басып торган кызына:

— И, кызым, күз нурым, рәхмәт сиңа! Нәселебезне мактауларга күмдең, исемебезне кайларга кадәр күтәрдең, исән-сау гына йөреп, тизрәк өебезгә кайт, балам! — дип куйды.

Иртәгесен Галимә Шөгерованың Европа чемпионы булуы турында газета хәбәрен укып утыра идек, телефон шалтырады. Трубканы алуга Галимә тавышы ишетелде. Ул шат һәм көр тавыш белән исәнлек-саулык сорашты.

— Испаниядән бүген иртә белән кайтып җиттек. Аэропортка төшү белән сезгә шалтыратырга ашыктым. Әле Мәскәүдә булабыз. Комсомолның Үзәк Комитетына барабыз, киностудиягә дә чакырдылар, бик күп котлау телеграммалары алдым, — диде кыз.

— Безгә дә килде алар, кызым. Кайчан кайтасың! — Нәҗибә ханым әле һаман дулкынлана иде.

— Озакламыйм, әни! Сагындым сезне!..

Нәҗибә ханым телефон трубкасын әкрен генә куйды да, безнең сорауны да көтмичә, сөйли башлады...

Галимә 1953 елның 8 ноябрендә Омск шәһәрендә туа. Семьяда шатлыкның иге-чиге булмый. Чөнки беренче бала була ул. Әтисе Әхмәтгәрәй, әнисе Нәҗибә кызларын укытучы итәргә хыялланалар, балага педагоглар турында китаплар укырга кушалар. Әмма Галимәне башка нәрсә кызыксындыра. Ул кече яшеннән үк нәфис гимнастика белән шөгыльләнә башлый. Әле икенче класста укыганда ук туп белән гимнастика ясап, укытучысын гаҗәпкә калдыра кыз. Укытучы киңәше белән ул Омск шәһәрендәге балалар өчен оештырылган гимнастика мәктәбенә йөри. Галимә бу һөнәрне бик яратып, бик теләп өйрәнә. Ләкин көннәрнең берендә шундый хәл туа: Галимә гимнастика мәктәбенә йөрми башлый. Борчылып килгән тренер Галина Павловна Горенкова менә нәрсә белә: шук малайлар Галимәне куа башлаганнар. Ул ике катлы өйнең түбәсенә менгән. Малайлар да менә башлагач, шуннан сикергән һәм аякларын авырттырган.

Ярты елдан соң гына тынгысыз кыз яңадан гимнастика мәктәбенә йөри башлый. Һәм, шул көннән башлап, мәктәп күләмендәге бер генә ярыш та Галимәсез узмый. Инде 7—8 классларда укыганда район һәм өлкә күләмендә нәфис гимнастика буенча уздырылган ярышларда ул беренче урынны ала. Шул ук елларда СССР күләмендәге ярышларда да катнаша башлый һәм тренерларны, судьяларны таң калдыра. Тамашачылар аңа озак итеп кул чабалар, чәчәкләргә күмәләр.

* * *

Омск шәһәренең 134 нче мәктәбе укучысы Галимә Ленинградта һәм Мәскәүдә, Тбилисида һәм Бакуда, Алма-Атада һәм Дүшәмбедә үткәрелгән ярышларда да беренче урынны алып, алтын медальләр белән бүләкләнә. Таҗик кызлары аңа багышлап җырлар җырлыйлар, азәрбайҗан шагыйрьләре шигырьләр язалар, Ленинград һәм Мәскәү журналистлары очерклар бастыралар, казах музыкантлары думбрада мактыйлар. Галимә исә бу зур уңышларга карап масаймый, яңадан-яңа күнегүләр ясый. Мәскәүдә үткән уңышлы чыгышлардан соң атаклы спорт мастеры Елизавета Алексеевна Облыгина Галимәнең тренеры Галина Горенковага болай ди:

— Бу кызның киләчәге бик өметле. Тырышып эшләсә, бөтен дөньяны таң калдыруы мөмкин! Бу кызны сез ничек кенә булса да саклагыз!

Елизавета Алексеевна әйткән бу сүзләрнең дөреслеген Галимә үзенең чыгышларында раслый. Ул 15 яшендә Болгариягә бара, атаклы дөнья чемпионнары белән очраша, яңа төр спорт күнегүләре ясый. Һәм, ниһаять, Варна шәһәрендә үткәрелгән дөнья чемпионатында катнаша.

Каушый, дулкынлана. Каушамаслык та түгел шул. Моңа кадәр дөнья чемпионатындагы атаклы гимнасткалар белән очрашканы юк иде бит аның.

Көткән көн дә килеп җитә. Дөньяның барлык радиолары, телевизорлары 15 яшьлек кызның ярыш аренасына чыгуын хәбәр итәләр. Галимә башта туп белән бик оста чыгыш ясый. Аның бу чыгышын тамашачылар алкышларга күмәләр. Аннары тасма белән чыгышын судьялар гаҗәпкә калып карыйлар. Кыршау белән ясаган чыгышларында да Галимә югары балл ала. Менә ярыш нәтиҗәләре яңгырый:

— СССРдан килгән 15 яшьлек Галимә Шөгерова югары күрсәткечләргә ирешә һәм дөнья чемпионы дигән мактаулы исемгә лаек булды!

Бөтен зал Галимәне алкышлый. Дөнья газеталары Галимә Шөгерованың уңышлары турында язып чыгалар.

Ә хат ташучы төне буе Галимә туган йортка котлау телеграммалары ташый.

Галимә Варнадан өч алтын, берничә көмеш медаль һәм дөнья чемпионы дипломы алып кайтты. Аңа СССРның атказанган спорт мастеры дигән мактаулы исем бирелде.

Чемпион кыз яңадан-яңа күнегүләр эшләвен дәвам итә. Ул Советлар Союзының йөзләрчә шәһәрләрендә, Америка, Англия, Франция, Германия Демократик Республикасы, Чехословакия, Венгрия һәм башка илләрдә булып, нәфис гимнастика буенча ярышларда һәрчак беренче урынны яулый һәм алтын медальләр белән бүләкләнә.

* * *

1973 ел. Роттердам шәһәре. Монда дөньяның атаклы спорт мастерлары җыйналган.

Данлы «Ахой» спорт комплексының көчле прожекторлар белән яктыртылган зур залында кара күзле, кара кашлы, нәфис гәүдәле Галимә дә бар. Шөгеровага нибары егерме яшь. Ул дулкынлана, башта төрле уйлар... Исемнәре бөтен дөньяга яңгыраган гимнастлар. Алар бүген дөнья чемпионатында көч сынашалар. Менә иң югары балл алган абсолют чемпион Мария Гигова. Кая инде аны узу, дип уйлый кыз. Шул чагында аның исеме яңгырый, кызны залга чакыралар.



«Матур булыгыз, кызлар!» Галимәнең журнал укучыларына теләге шул.

Галимә бөтерелеп килеп чыга да туп белән гаҗәеп җитез хәрәкәтләр ясый башлый. Тамашачылар һәм судьялар хәйран калалар. Алар алдында гүя җир кызы түгел, ниндидер тылсымлы әкият кызы чыгыш ясый шикелле. Галимә яңа бөтерчекләр ясаган саен кул чабалар, ә ахырында бөтен зал аякка баса һәм ун минут буена кызны алкышлый. Аны аренага кабат-кабат чыгаралар, төрле телләрдә рәхмәт әйтәләр. Бу ярышта да Шөгерова, иң югары балл җыйнап, дөньяның абсолют чемпионы дигән мактаулы исемне ала. Галимәнең җиңүе хөрмәтенә тагын Советлар Союзы гимны яңгырый.

Бу аның өченче мәртәбә чемпион булуы иде.

* * *

Дөнья һәм СССРның абсолют чемпионы, СССРның атказанган спорт мастеры Галимә Шөгерованың тормышында да соңгы елларда, шәхси борчылуларын алыштырып, шатлыклы вакыйгалар еш була. Ул комсомолның XVII һәм XVIII съездларында делегат булып катнаша. Залга спорт байракларын алып кергәндә беренчеләр рәтендә килә. Гаванада үткәрелгән яшьләр фестивалендә дә була Галимә... Спорт белгечләре аның турында китаплар язалар, радио-телевидениеләрдә Галимә исеме еш яңгырый. Шундый истәлекле көннәрдә кыз үзе шикелле үк чемпион егет белән таныша. Алар яшьлекнең иң гүзәл көннәрен ярышларда үткәрәләр, кино-театрларда булалар, сандугачлар сайрап торган бакчалардан узалар, чит илләргә баралар... һәм көннәрнең берендә егет Галимәгә тәкъдим ясый.

Галимә Шөгерова белән танылган велосипедчы, Казан ягы егете Ринат Шәрәфуллин гөрләтеп туй итәләр.

Шөгерова тормышка чыккач та спорт белән шөгыльләнүен ташламый. Ул институтта да укый, җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша — комсомолка кыз барына да өлгерә.

Соңгы елларны Украина спортсменкасы Ирина Дерюгина, Галимәне узып, беренчелекне яулый. Шул көннән башлап юньләп йоклый да алмый Галимә. һаман күнегүләр ясый, укый, эзләнә. Кызның күңелендә беренчелекне алу өмете яши. Ял-йокы күрмичә туктаусыз нәфис гимнастика күнегүләре ясавын күреп торган әнисе Нәҗибә ханым кызына болай ди:

— Ул кадәр күнегүләр ясап үзеңне-үзең бетерәсең бит, кызым. Дөнья чемпионының икенчесе булу да ярый бит. Ул кадәр эшләвеңә авырып китәрсең дип куркам.

— Мин беренче урынны бирәүгә дә бирергә теләмим, әни! — ди Галимә.

* * *

һәм ул менә тагын үзенең максатына ирешә: Испаниядә Европа чемпионы исемен (инде ничәнче кат!) яулап кайта. «Комсомольская правда» газетасының аңа багышланган «Гүзәллекнең җиңүе» мәкаләсендә мондый юллар бар:

«Галимә Шөгерова, нәфис гимнастика тарихында беренче буларак, Европаның абсолют чемпионы булды. Ярыштан соң ул Спорт сараеның аренасы читендә сулкылдап елап җибәрде. Беркем дә аны юатырга батырчылык итмәде, чөнки аның күзләрендә шатлык яшьләре иде...»

Галимә турында тагын шуны да әйтәсе килә. Без аның бүлмәсендәге сувенирларны күреп таң калдык. Кайсы илләрдән, кайсы шәһәрләрдән генә бирелмәгәннәр алар. Фоторәсемнәрнең исә исәбе-хисабы юк. Без ул рәсемнәр арасында бик таныш кешеләрне — дәүләт җитәкчеләрен, атаклы спорт осталарын, әдәбият һәм сәнгать вәкилләрен, Советлар Союзы һәм Социалистик Хезмәт Геройларын, Ленин һәм Дәүләт премиясе лауреатларын күрдек. Галимә Әхмәтгәрәй кызы Шөгерова да — алар арасында. Аңа тагын да зур уңышлар, бәхет һәм шатлык теләп калабыз!

Омск-Казан.

ОКТЯБРЬ ҖИМЕШЕ

Таһир АХУНҖАНОВ,
КПССның Башкортстан өлкә комитеты секретаре.

ИСЕМЕ: Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы.
ТУГАН ЕЛЫ: Дәһшәтле 1919 елның март ае.
ТУГАН ҖИРЕ: Көньяк Урал. Европа белән Азия тоташкан урын.
ХАЛКЫ: дүрт миллионга якын кеше.
МИЛЛӘТЕ: Йөзгә якын милләт яши.
БҮЛӘКЛӘРЕ: Ике тапкыр Ленин Ордены, Октябрь революциясе һәм Халыклар дуслыгы орденнары белә бүләкләнгән.

Республикабыз турында сүз башладыкмы, башкорт халык шагыйре, дәүләт премиясе лауреаты Мостай Кәримнең табигатьтә булсын, тарихта һәм халыклар язмышында булсын олы һәм вак нәрсәләрнең бердәмлеген гаҗәп тә төгәл гәүдәләндерүче чал Урал турындагы юллары искә төшә.

«...Европадан Азиягә җилләр исә,
Европадан Азиягә болыт күчә.
Мәзәк итеп карап торам
Кечкәй генә кырмыскага
Йөк күтәреп чыгып бара
Азиядән Европага.
Ә соң кояш җирне ничек тигез нурлый,
Европага, Азиягә бүлеп тормый.

Ә яңгырдан соң, дип дәвам итә шагыйрь үзенең юлларын, салават күпере ике кыйтга аша алтын күпер суза.

Менә шушы урында-таш кыялар, карурманнар, очсыз — кырыйсыз далалар, зәңгәр күлләр, елгалар куенында моңлы, зарлы башкортлар мең еллап яшәгәннәр. «Анда, Агыйдел буенда, — дип сокланган Максим Горький, — шундаен да гүзәллек ки, бер генә түгел, йөз мәртәбә шаккатырсың». Ә шушында ук XX гасыр таңын каршылаган икенче рус язучысы Н. Крашенинников «И, хәзрәтләр иле, калымнар иле, кол хатын-кызлар иле, тимердән дә ныграк томаналык иле!.. Кайчан иңәр монда яктылык, кайчан?..» дип сызланып язган.

Якташларының авыр язмышын үз күзләре белән күргән әдипнең күкрәгеннән сыкрап чыккан бу сүзләргә тарих шаһит. 1916 нчы елда, мәсәлән, Уфа губернасындагы 100 крестьянның унөче җирсез, 22 се атсыз, сигезе бернинди мал-мөлкәтсез иде бит. 1913 нче елда нибары унике башкорт баласы урта мәктәптә укыган. Үз илендә килмешәктәй яшәгән бу халык тумыштан килгән сәләтенә, куәтенә богау салган кара көчләргә каршы рус кардәшләре белән бергәләп тә көрәшеп карый. 1557 елны ул үзе теләп Рус дәүләтенә кушыла. Ерак бабаларыбызның бу зирәк адымы рус һәм башкорт халкын бер-берсенә якынайту, туганлаштыру өчен юл ача. Үзләренең якты киләчәкләре өчен, тигез хокук алу өчен халыкларның бердәм көрәше тарих сәхифәләренә уелган. Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы герое — башкорт улы Салават Юлаевның исеме легендар батырлар исемлегенә теркәлгән.

Ләкин бу стихияле көрәшләр самодержавие тарафыннан рәхимсез рәвештә бастырыла килә. Бары тик XX гасыр башында рус эшчеләр сыйныфы җитәкләгән Бөек Октябрь революциясе генә аңа күзен ачарга, аякка басарга мөмкинлек бирде. Башкортстандагы социал-демократик хәрәкәтнең үсешенә Владимир Ильич Ленин якыннан торып ярдәм итте. 1900 нче елны ул Уфада ике мәртәбә булды. Политик партиянең нинди булырга, теге яки бу шартларда аның ничек көрәшергә тиешлеге турында төгәл, ачык фикерне Уфа социал-демократлары беренче тапкыр В. И. Ленинның үз авызыннан ишеттеләр. В. И. Ленинның һәм шушында сөргендә яшәгән Н. К. Крупскаяның турыдан туры җитәкчелеге астында Башкортстанда профессиональ революционер-большевиклар үсеп чыктылар. Моңа мисал итеп А. Д. Цюрупа, И. С. Якутов, А. И. Свидерский, бертуган Кадомцевлар, Т. С. Кривов һәм башка бик күп большевикларны санап китәргә мөмкин.

Бөек Октябрь Социалистик революциясенең җиңүе хезмәт ияләренең гасырлар буе хыялланган якты теләкләрен тормышка ашырды. 1919 нчы елның 20 нче марты башкорт халкының иң истәлекле көннәреннән берсе булды. Бу көнне В. И. Ленин Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү турындагы документка кул куйды.

Башкортстан республикасы туган көненнән алып Коммунистлар партиясенең һәр вакыт игътибар үзәгендә булды. Совет властеның беренче елларында ук В. И. Ленинның күрсәтмәсе белән республиканың табигый байлыклары өйрәнелә башлады. Егерменче һәм утызынчы елларда нефть, ташкүмер, тимер һәм башка казылма байлыклар ятмалары ачылды һәм эшчеләр сыйныфының, колхозчы крестьяннарның, интеллигенциянең һәм илебездәге барлык халыкларның тырышлыгы нәтиҗәсендә беренче бишьеллыклар чорында ук алга киткән авыл хуҗалыгы, югары культуралы индустриясе булган куәтле республикага әверелде.

Бөек Ватан сугышы елларында башкортлар дошманга каршы батырларча көрәштеләр. Республиканың 250 дән артык кешесенә Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Әочучы-штурмовик Муса Гәрәев бу мактаулы исемгә ике мәртәбә лаек булды. Уфа комсомолецы Александр Матросовның батырлыгы бөтен дөньяны таң калдырды. Офицерлар арасында беренчеләрдән булып аның батырлыгын икенче комсомолецыбыз Миннегали Гобәйдуллин кабатлады.

1941-43 елларда Уфада халыкара коммунистик хәрәкәтнең штабы-Коминтерн башкарма комитеты урнашты. Монда революцион хәрәкәт җитәкчеләреннән Георгий Димитров, Пальмиро Тольятти, Вильгельм Пик, Долорес Ибаррури, Морис Торез, Клемент Готвальд һәм башка коммунистлар эшләделәр. Коминтернның радиостанциясе бөтен дөнья халыкларын фашизмга каршы, ирек һәм бәйсезлек өчен көрәшкә чакырып шушыннан торып мөрәҗәгать итте.

Сугыштан соңгы бишьеллыкларда Башкортстан хезмәт ияләре яңадан яңа гүзәл уңышларга ирештеләр. 1950 елда ук өлкәдә промышленность товарлары җитештерү сугышка чаклы булган чорга караганда 3,6 мәртәбә үсте. Нефтьнең яңа чыганакларын үзләштерү зур темплар белән башланды. Нефтехимия, энергетика, машиналар төзелеше, җиңел һәм азык промышленносте гигант адымнар белән алга китте.

Республикабызда Октябрьск, Салават, Нефтекамск, Күмертау, Туймазы, Учалы кебек берсеннән берсе төзек һәм ямьле яңа калалар калыкты. Соңгы ике бишьеллык арасында гына да 570 яңа предприятия сафка басты. Алар арасында Кармановск ГРЭСы, Бәләбәйдәге «Автонормаль», Туймазыдагы «Химмаш» кебек гигантлар бар. Республикабыз промышленносте җитештергән продукция илебезнең төрле почмакларына озатыла, җитмешкә якын чит дәүләтләргә чыгарыла.

Авыл хуҗалыгы продуктлары җиитештерү буенча Башкортстан РСФСР составына кергән өлкәләр, автономияле республикалар, крайлар арасында иң алдынгылар рәтендә бара. Тугызынчы бишьеллыкның өч елында игенчеләребез ил амбарларына биш миллион тоннадан артык ашлык салдылар. Л. И. Брежнев 1978 елның ноябрь Пленумында, югары уңыш өчен көрәшүче алдынгы игенчеләр белән беррәттән, Башкортстан авыл эшчәннәрен дә билгеләп үтте. Һава шартларының уңайсыз килүенә карамастан, республикабыз игенчеләре, узган елда рекордлы уңыш үстереп, дәүләткә 2,8 миллион тонна ашлык саттылар.


Бөек Октябрь казанышлары нәтиҗәсендә республикада формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культура үсте, чәчәк атты. Бүгенге Башкортстанда һәрбер өченче кеше укучы санала. Тугыз Югары уку йортында 100 гә якын, ә техникумнарда, профессиональ-техник училищеларда 250 төрле белгечлек буенча меңәрләгән кадрлар хәзерләнә. Башкортстан китап нәшрияты узган бишьеллыкта гына да мең ярымнан артык исемдәге китаплар бастырып таратты. Республикабызда әсәрләре халык тарафыннан яратылып укыла торган йөздән артык язучы иҗат итә.

Л. И. Брежнев, халыкның рухи байлыгына әверелгән әсәрләр иҗат итүче атаклы язучыларыбыз белән беррәттән, шагыйребез Мостай Кәримнең дә исемен атады. Башкорт драматургларының геройлары дистәләгән телләрдә сөйләшә. Галимнәребезнең ачышлары илебез халкының уртак казанышына әверелде.

Бездә унтугызынчы гасырда башкорт җире буйлап сәяхәт иткән Глеб Успенскийның язып калдырган юлларын еш кына искә алалар. «Харап була бит башкорт, һичшиксез харап булачак бит бу башкорт», дигән ул шул замандагы ач-ялангач бичара халыкны күреп. Патша хөкүмәтенең колониаль политикасы астында изелгән башкорт та һәм башка кайбер халыклар да бәлки харап та булырлар иде. Әмма Коммунистлар партиясенең ленинчыл зирәк милли политикасы аларның язмышын тамырыннан үзгәртте, СССР да барлык халыкларның үсешенә юл ачты, караңгыдан яктылыкка, хәерчелектән байлыкка, изелүдән, кимсетелүдән ireккә-хөрлеккә алып чыкты.

Совет Башкортстаны үзенең җиденче дистәсенә экономик һәм культура ягыннан үсеп, чәчәк атып гигант адымнар белән баса. Алда — якты киләчәк, яңа үрләр. Алар бөек Ленинның, коммунистлар партиясенең зирәк политикасы белән алдан билгеләнгән. Бөек Октябрьның гүзәл бер җимеше булган Социалистик Башкортстан шул юлдан кыю атлый.

УФАНЫҢ 30 МЕҢНӘН АРТЫК УКУЧЫ БАЛАЛАРЫ ҮЗЕШЧӘН СӘНГАТЬ ҺӘМ СПОРТ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘ. МОНЫҢ ӨЧЕН АЛАРГА БӨТЕН ШАРТЛАР ТУДЫРЫЛГАН.





Археология түгәрәгендә дәресләр бара.



Фехтование буенча шәһәр ярышында беренче урынны алган Гөлнара Ишкузина.

ТУГАНДАШ БАШКОРТСТАНГА 60 ЕЛ

Балалар иҗат йортының рәсем сәнгате студиясендә.







Кече фәнни хезмәткәр Роза Бакиева 10 нчы класс укучысы Әлфирә Әхмәтшинага тәҗрибә үткәрергә булыша.

Институт лабораториясында.


Рифкат ЯКУПОВ фотолары



Укучыларның с




җәмгыяте членнары.



«КамАЗ кызы»



«Кош караучы»



ВИКТОР АРШИНОВ РӘСЕМНӘРЕ

Талантларны илһамландырырдай гүзәлләр кайда гына очрамый безнең көннәрдә. Яшь рәссам Виктор Аршинов, күңелендә бөреләнгән хисләргә этәргеч эзләп, данлы КамАЗ җирендә күп йөргән. Ниһаять, рәссам әсәрләре арасына төзүче кыз рәсеме өстәлә. Көнебезнең үзе булып. Чынбарлыгыбызның нигезен тәшкил итүче булып. Кызлар шәһәр сала, завод төзи. Образлары фидакарьлек үрнәге булып Татарстан тарихына кереп кала. Рәссамны бигрәк тә кызларның тырышлыгы, уңганлыгы дулкынландыра. Аның «КамАЗ кызы», «Кош караучы» портретлары шул турыда сөйли. Башка картиналар белән бергә бу рәсемнәр дә күп кенә күргәзмә залларында булды. 70 нче еллар геройларын — Татарстан кызларын күп тамашачылар күреп сокланды.

Виктор балачактан ук әдәбиятны ярата. Герой шагыйрь Муса Җәлил иҗаты белән таныша. Аның шигырьләрен укый. Шагыйрьне шагыйрь иткән образларга рәссам җан кертә. Мәскәүдә укыганда диплом эшенең тулысынча Җәлил иҗатына багышлануы аны Казанга алып килә. Художникны күптән дулкынландырган «Алтынчәч» картинасы биредә туа.


Аршинов картиналарына карыйсың да бер минутка тын каласың. Рәсемнәрдәге кызлар сиңа ниндидер серләрен чишәр төсле. Шуңа ышанасың, көтәсең.

Рәссам үзе дә илебез киңлекләрендә, Татарстан җирендә күп йөри. Казанга кайткач, Тукай, Җәлил томнарын кулына ала. Художниклар союзындагы секретарьлек эшләрен дә бирелеп башкара ул. Әмма аның тормышындагы иң ләззәтле минутлар — иҗат вакыты. Кулына пумаласын алганчы ул туктап тын кала. Аның бөтен барлыгы иҗатка юнәлә. Картиналары исә заманга, кешеләргә әйтер сүзе. Игътибар биреп карагыз әле, рәссам сезгә матурлык серләрен ача...

Сынлы сәнгатьнең нинди генә төренә тотынмасын, Виктор һәр сызыкны бик төгәл үткәрә, һәр ноктаны күп уйлаганнан соң гына куя. Рәссам холкындагы җитдилек, хезмәтенә ифрат җаваплы каравы әсәрләренең төгәллегеннән дә, төсләрнең килешле төшерелүеннән дә, эчтәлекнең тәмам ачылып җитүеннән дә яхшы аңлашыла. Биредә тәкъдим ителгән әсәрләр дә («Кош караучы», «КамАЗ кызы») рәссам иҗатының күп сыйфатларын күрергә ярдәм итәр.

Илдар ӘХМӘДИЕВ, рәссам.

Илгиз Кәлимуллинга 50 яшь



Илгиз КӘЛИМУЛЛИН

Һәрбер чишмә өскә бәреп чыкканчы җир астыннан күпме юл үтә, күпме катламнарны тишә. Илгиз Кәлимуллин поэзиясе дә авыр тау катламын тишеп, җир өстенә бәреп чыккан дәртле чишмә кебек. Чишмә юлы җиңел түгел. Олы елгаларга суыкны саф килеш китереп җиткерү өчен туктаусыз агарга кирәк. Әз генә тынып тордыңмы — саегасың, суыкның сафлыгы кими. Илгиз Кәлимуллин шушы хакыйкатьне яхшы белеп эш итә. Ул чишмә кебек тынгысыз, омтылучан. Шуңа да аның әсәрләрен поэзия сөючеләр көтеп алалар, яратып укыйлар. Бүген шагыйрьгә 50 яшь тулган көндә аның иҗат юлы озын, дәвамлы булуын телибез.

Яр буенда

Матур алсу коену костюмыннан
Яр буенда утыра бер ана.
Ә малае уйный дулкын белән
Үз бәхетеннән куана-куана.

Көлә-көлә сулар чәчрәтә ул,
Вак тамчылар сибелә як-якка.
Шук малайның нәни учларыннан
Салават күпере сузыла еракка.

Сокланырлык матур күренеш бу,
Әйтерсең лә
Бәхет үзе уйный елгада.
Ана белән бала шатлыгыннан
Зуррак шатлык юктыр дөньяда.

Каен төбендә

Сөйгәнемнең өй түрендә,
Кунып каенга,
Сандугач сайрый, бакчаны
Күмеп җыр-моңга.

Кызу көн алмашу белән
Йолдызлы кичкә,
Мин киләм каен төбенә,
Түзмичә хискә.

Буяулы капкалардан гел
Күз алмый көтәм.
Елмаер да килеп чыгар
Яныма иркәм.

Китәрбез аның белән без
Бакча юлыннан.
Мәхәббәт юлы салыныр
Мәнә шушыннан.

Әй, җырчы кошчыгым минем,
Сайра син яме,
Сөйгәнемә белдер шулай
Минем килгәнне.

Классташ дустыма

Яшәсәк тә төрле урамнарда,
Укыдык без бер үк класста.
Шул дуслыкны искә аламын мин
Чәчләремә чаллар кунгач та.

Хәтеремдә, салкын бураннарда
Озата килә идең өемә.
Үземне мин көчле сизә идем
Таянганда синең иңеңә.

Сизелми дә еллар үтеп китте,
Син кайдадыр — хәзер белмим дә.
Бәлки иген үстерәсеңдер син
Муллык артсын өчен илемдә.

Бәлки тирән җир катламын тишеп,
Эзлисеңдер кыйммәт җир маен.
Кая китеп, кайда эшләсәң дә
Сынатмыйсың булыр мөгаен.

Әгәр берәр мине искә алсаң:
— Читтә калды бу, — дип, —
көрәштән:
Үпкәләрмен сиңа бөтенләйгә,
Дустым диеп кабат эндәшмәм.

Дөрес, миңа бик-бик авыр була,
Сыкранып та куям кайчакта.
Тик җырлардан юллар түши-түши
Якынаям олы максатка.

Син дустымнан калышмаска теләп
Авыруны тырышам җиңәргә.
Зарланмыймын үз язмышымнан да —
Яңа дусларым бар тирәмдә.

Тик кайвакыт шулар арасыннан
Син күренгән кебек буласың.
Чакырасың төсле тышка мине
Болгый-болгый мәктәп сумкасын.

Фәнис ЯРУЛЛИН тәрҗемәләре.

БАНАТ

Любовь КОВАЛЕНКО



Рәшит ИМАШЕВ рәсеме.

Украин язучысы Любовь Коваленко Бөек Ватан сугышы чорында Татарстанга, Азнакай районына эвакуацияләнгән була. Авыр елларда үзләре белән барысын да бүлешкән, җылы өйләреннән урын биргән юмарт күңелле, ачык йөзле кечкенә генә татар авылы кешеләрен ул һәрвакыт хөрмәт белән искә ала. Любовь Коваленко хәзер сугыш елларында әти-әнисез калган украин балалары Оксана белән Олесьның язмышын сурәтләгән повесть тәгәллләп килә. Укучыларыбызга шул әсәрдән бер өзек тәкъдим итәбез.

Бүтән арбаларны без шәһәр чыккач кына куып җиттек. Атлар, юыртудан туктап, җайга гына атлый башладылар. Олаучы малаебыз дилбегәсен бушатты да, инде иркенләп танышсак та була дигәндәй, безгә таба борылыбрак утырды. Карашыннан сизеп алдым, Олесь белән мине ул, ахрысы, бик үк өнәп бетермәде. Ә Рекска менә исе китте, телен шартлатып:

— Ай-яй, нинди шәп эт! — дип куйды. — Минем абый да шундый эт белән чик буенда хезмәт итә! Фоторәсемен дә җибәргән иде.

Олаучыбыз русча шактый ук әйбәт сөйләшә иде.

— Исемең ничек? — диде ул миңа карап.

— Оксана.

— Ә синеке, малай?

— Олесь. Ә этнең исеме — Рекс.

— Ә мине Миргазиан, диләр.

Ул бездән барысын да сорашты: каян килгәнбез дә әти-әниләребез кайда?.. Һәммәсен сөйләп бирдек.

Иксез-чиксез кырлар, болыннар аша, эреле-ваклы урманнарны кичә-кичә озак кына бардык. Бу яклар инде көзгә кергән иде. Агачлар сары шәлләрен ябынганнар, басулар бушап калган. Хәер, кайбер җирләрдә әле булса ташылып бетмәгән чүмәләләр күренгәли.

— Барысы да фронтка китте. Хатыннар белән малайлар да картлар гына калды, — ди Миргазиан, кашын җыерып.

Авылга кич кенә кайтып кердек. Күп өйләрнең тәрәзәләрендә утлар җемелди. Кайдадыр сыерлар мөгерәве, кычкырып сөйләшкән кеше тавышлары ишетелә. Авыл советы булса кирәк, түбәсендә кызыл флаг җилфердәгән бер йорт янына җитеп килдебез. Болдыр өстендә ике ир тәмәке тартып тора. Болдыр тирәсен исә хатыннар сырып алган. Тик безнең кебек эвакуацияләнеп килүчеләрдән берәү дә күренми. Аларны инде, ахрысы, урнаштырып бетергәннәрдер.

Миргазиан атларны туктатуга, тәмәке тартып торучы ирләрнең берсе баскыч өстеннән безнең янга төште. Ул татарларга бөтенләй диярлек охшамаган аксыл чәчле яшь кенә бер кеше иде. Пинжәгенең буш бер җиңен кесәсенә тыгып куйган. Безгә карап алды да Миргазианнан нидер сорады. Малай нәрсәнедер раслап башын какты.

— Ярый, бик яхшы булган, — диде ир русчалатып.

Миргазиан инде китәм дип атларын кузгатырга гына торганда, сыңар куллы кеше янына бер хатын килеп, бармагы белән әле миңа, әле Олеська, әле Миргазианга таба күрсәтә-күрсәтә кызу-кызу сөйләргә кереште. Ә ир кепкасын басыбрак киде дә, бер безгә, бер Миргазианга карап, нәрсә дип әйтергә дә белмичә, аптырап калды. Ул арада Миргазиан да, чыбыркы сабы белән хатынга таба төртә-төртә, ачуланып нидер сөйләргә тотынды.

Бу әрләшүләргә колак салсам да, мин берни дә аңлый алмадым. Нәрсә булды икән дип борчыла ук башлаган идем. Шул чагында ир кеше миңа карап нидер әйтте. Миргазиан да, әлеге хатын да, әрләшүдән шундук туктап, Олесь белән миңа текәлделәр. Мин иңбашымны җыерып:

— Без бер нәрсә дә аңламыйбыз, — дидем.

Барысы берьюлы көлешергә тотындылар. Алар безнең татарча бер авыз сүз дә белмәвебезне бөтенләй онытканнар.

Ә тавыш менә нәрсәдән чыккан: Миргазиан безне үзләренә алып кайтырга тели, ә хатын моңа каршы төшә, сезнең семьягыз болай да ишле, ә мин бер ялгызым, өем дә зуррак, миндә торсыннар, ди икән.

Һәм менә сыңар куллы кеше, — соңыннан белдек, ул колхоз председателе икән, — бу бәхәсне ничек чишәргә белмичә, безнең үзебезгә мөрәҗәгать итте:

— Кемгә барасыз? Миргазианнаргамы, әллә Банатларгамы?

Бер малайга, бер Банатка карап, уңайсызланып калдым. Миргазианны минем һич тә үпкәләтәсем килми иде. Әмма бит аларның семьясы ишле диләр. Рекска ничек караячаклары да билгесез.

— Миргазианнарга барыйк, — диде миңа Олесь пышылдап кына.

Мин Банатка карап алдым. Ул борчылып Олесьны күзәтә иде. Мин аны шундук аңлап алдым, әйтерсең лә минем үземдә дә аналар хисе уянды. Мин дә шул хатын-кыз өммәтеннән ич. Банат безнең ятимнәр икәнебезне белә, шуңа күрә ул безне үз янына сыендырырга тели иде. Һәм чыннан да, Банат янында Олеська бик яхшы булачак, ул хәзер нәкъ менә ана назына, аналарча кайгыртучанлыкка мохтаҗ ич. Фронтка китсәм дә аның өчен мин тыныч булачакмын. Ә сугыш беткәч, кайтырмын да алып китәрмен. Шуларны уйладым да:

— Миргазиан, син инде үпкәләмә. Без синең белән һәрвакыт дуслар булырбыз. Без Банат янына барабыз, — дидем. Банат барысын да аңлады, болай да сөйкемле йөзе тагын да яктырып, нурланып китте һәм шундук:

— Әйдәгез, әйдә, — дип өенә ашыктыра башлады.

Әмма Олесь бу хәлгә бер дә риза түгел иде. Шуңа күрә ул, Банатның кире уйлавына өметләнеп:

— Безнең этебез дә, Лиска исемле мәче баласы да бар. Рекс бик зур һәм бик күп ашый. Ә Лиска һаман сөт кенә сорап тора, — дип такмакларга тотынды.

Малайның бу беркатлы хәйләсенә барысы да елмаеп куйдылар. Ә Банат, моңа бер дә исе китмичә:

— Миндә барысы да җитәрлек. Мин колхозда бик әйбәт эшлим. Ышанмасаң, әнә председательдән сора, — диде.

Ләкин без инде сорашып тормадык, ашыга-ашыга арбадан төшә башладык. Хатыннар бозау чаклы Рекска сагаеп карыйлар иде.

Миргазиан ачынып дилбегәне селтәп җибәрде һәм арба, авылның бердән-бер урамы буйлап, дөберди-дөберди китеп барды. Ә без Банатка иярдек...

Өй янында нык итеп эшләнгән өр-яңа капка. Ә капкадан ары бер ни дә юк — койма да, киртә дә. Шулай да без барыбыз да бик тантаналы рәвештә капкадан кердек. Соңыннан аны Банат әйбәтләп кенә ябып куйды. Йорт чыннан да зур, яңа иде. Бүрәнәләреннән хәтта шушы көзге кичтә дә җылылык сирпелә төсле. Әченә кермәс борын ук өйнең җыйнаклыгы, җылылыгы сизелеп тора.

Чыннан да, өйдә бик җылы иде. Мич ягып җибәргәннәр. Ә дөрләп янган мич каршында, кулына камырлы табак тотып, озынча гына гәүдәле өлкән яшьләрдәге бер хатын тора. Идәннәр сап-сары итеп кырып юылган. Без, түргә узарга кыймыйча, ишек төбендә туктап калдык. Банат исә башмакларын салды да күрше бүлмәгә йөгереп кереп китте. Ә теге өлкән хатын, һаман да шул табагын тоткан килеш, дәшмитынмый безне күзәтә иде.

— Исәнмесез! — дидек без, әдәпле генә итеп.

Хатын башын селкеп елмаеп җибәрде.

Ул арада ниндидер төенчек тотып Банат килеп чыкты да:

— Әйдәгез, мунчага! Җылынырсыз, бик әйбәт булыр, — дип безне ашыктыра башлады.

Олесь мәче баласын куеныннан чыгарып идәнгә җибәрде. Ул иснәнә-иснәнә өй белән таныша калды. Ә без кичке караңгылыкта чак кына шәйләнә торган сукмактан бәрәңге бакчасы артындагы мунчага киттек.

Башта без каен себеркесе белән бик әйбәтләп чабындык. Аннары мунчала белән ышкый-ышкый Олесьны юындырдык. Шуннан соң Банат малайны ак җәймәгә, җылы юрганга төреп, алачыкка чыгарып утыртты...

Мунчадан тәмам җылынып, күңелебез күтәрелеп кайттык. Өстәлдә самавыр шаулап утыра. Өстәл уртасында — кызарып пешкән кабартма өеме. Мич буендагы озын эскәмиягә Лиска менеп кунаклаган. Ул түшәмдә эленеп торган лампа яктысына күзләрен кыскалый-кыскалый рәхәтлеккә чумып утыра иде. Рекс исә үзенең иләмсез зур гәүдәсе белән идәнгә сузылган да, озын, газаплы юлдан соң изрәп йоклый иде.

Өстәл янына утырышкан гына идек, өйгә яшь кенә ике хатын килеп керде. Ләкин алар түргә узмадылар, ишек катында Банат белән нидер сөйләштеләр дә, кызганып булса кирәк, безгә карап тора башладылар. Аннары берсе кесәләреннән биш йомырка алып миңа сузды. Ә икенчесе Олесьның итәгенә тутырып ук диярлек кыздырылган көнбагыш сипте һәм бер шакмак шикәр бирде.

Тагын бераз юандылар да дәшми-тынмый чыгып киттеләр.

Без сөтләп, баллап самавырдан чәй эчтек. Кабартмалар бик тәмле иде. Карчык аларны сүзсез-нисез генә безнең алга куя торды.

— Бу минем иремнең әнисе,— дип Банат елап җибәрде.— Һәлак булды ирем. Сугыш. Улым да юк, кызым да. Бер ялгызым.

Карчык аңа кырыс кына итеп карап куйды. Ләкин Банат үзенчә нидер такмаклый-такмаклый сулкылдап елый бирде.

Олесь белән без дә нәүмизләнеп калдык. Мин үз әниемне күз алдына китерергә тырышып карадым. Нишли икән ул хәзер? Әмма шәһәр фашистлар кулында булганда нәрсә генә эшли алсын икән ул. Моны күз алдына китерүе мөмкин түгел иде...

Тагын ишек шыгырдап куйды һәм, кулына сөтле шешә тотып, янә бер хатын килеп керде. Монысы да ишек яныннан гына безгә карап торгач, нидер әйтте дә кулындагы шешәсен Олеська тоттырды.

— Рәхмәт,— диде аңа Олесь татарчалатып. «Рәхмәт» сүзен ишеткәч, хатын ап-ак тешен ялтыратып елмаеп җибәрде. Миргазиан әнисе түгел микән әле. Бигрәк тә охшаган иде ул аңа. Хатын чыгып киткәч, бу турыда мин Банаттан да сорадым.

— Әйе, Миргазиан әнисе, — диде Банат.

Аннан соң, ахылдый-ухылдый, карт кына бер бабай килеп керде. Ул, ишекне яба алмыйча, бусага төбендә таптанатаптана озак кына маташты. Бабай култык астына сыңар киез итек кыстырган иде. Һәм менә ул, ниһаять, ишекне япты. Банат аңа шундук урындык китереп бирде.

Бабай утырды да киез итеген тез өстенә куйды.

Без аптырап калдык: нигә күтәреп йөри ул сыңар киез итекне?

Бабай безгә хәйләкәр генә елмаеп куйды да, фокус күрсәтүчедәй кыландырып, бер кулын киез итек балтырына тыкты. Без барыбыз, хәтта Рекс та, кызыксынып бабайга карап тора башладык. Ә карт ашыкмыйча гына киез итектән алсу-яшькелт төстәге ниндидер бер түгәрәк нәрсә чыгарып уч төбенә куйды. Аннары, бик кадерле, бик кыйммәтле әйберен биргән төсле, Олеська сузды.

Моны күргәч, Банат белән кайнанасының исләре китте.

— Ал, малай, аша, — диде бабай. — Яхшы кешегә бер нәрсә дә җәл түгел.

«Яхшы кеше» күчтәнәчне кыяр-кыймас кына алды. Мин дә иелеп күчтәнәчкә карадым. Помидор ич бу! Пешәр-пешмәс гап-гади помидор иде.

Бабай үзе дә, нәкъ бер сабый кебек сокланып, шул кечкенә генә помидорга карый иде. Мин гаҗәпсенеп Банатка таба борылдым. Ние бар соң моның, янәсе. Гадәти бер помидор. Ә Банат күчтәнәчтән күзен ала алмый, ә үзе кызукызу картка нидер сөйли. Ахрысы, аны мактый иде булса кирәк, бабайның авызы колагына җиткән. Әчтән-тыштан балкый иде ул бу минутта.

Ә без, кояшлы Украинада туып үскән кешеләр, моның чыннан да зур, кадерле күчтәнәч икәнен ул чагында белмәгәнбез шул. Без бит олау-олау, тау-тау помидорларны күреп шул кадәр күнеккән, аларның кайбер җирләрдә бөтенләй үсмәвен башыбызга да китермәгәнбез. Помидор монда да үсми. Үссә дә пешеп өлгерми икән. Аны яшел килеш өзеп алалар да җылы урынга куеп тоталар иде. Шуннан соң ул беркадәр пешә һәм бик кадерле, бу җирләрдә бик сирәк очрый торган ашамлык сыйфатында тотыла иде. Әлбәттә, хәзер инде Татарстанда да помидор үстерергә өйрәнделәр, анда да ул бик әйбәт пешә. Ләкин кырыгынчы елларда хәл бөтенләй икенче иде шул.

Тик соңыннан, әлеге күчтәнәчнең чын бәясен белгәч, помидоры өчен Рәхмәтулла бабайга үзебезнең кайнар рәхмәтебезне бер генә әйтмәдек. Анда яшәгән вакытта, әлеге шул иске киез итеген күтәреп, ул безнең янга һәр көнне килә һәм помидор белән сыйлап китә иде.

Рәхмәтулла бабайны без «үз бабаебыз» дип йөртә идек. Шулай ара-тирә Олесь берәр кружка бал күтәреп кайта иде.

— Каян алдың? — дим мин аңа кырыс кына.

— Бабай бирде, — ди.

— Нинди бабай? — дим, тагын да кырысрак итеп. Чөнки мин аны я теләнеп, янсә рөхсәтсез алып кайтадыр дип уйлый идем. Ул бит шундый: берәр әйбер ошадымы — сорый башлый, әгәр инде үзендәге әйбергә берәрсе кызыкса, һич тә икеләнмичә бирә дә җибәрә.

— Нинди, нинди... Безнең бабай,— ди Олесь канәгатьсез генә.

Безнең «үз әбиебез» дә бар иде — Мәрьям апа, Банатның кайнанасы. Ул безне оныклары кебек күрә иде. Ләкин Мәрьям апа русча әз-мәз аңласа да сөйләшә белми. Ә инде балалар арасында кайнашып, Олесь тиз арада татарча сөйләшергә өйрәнеп алгач, Мәрьям ападагы шатлыкның иге-чиге булмады. Ул аны һәрвакыт тәм-том белән сыйлый иде, дәрәҗәле бер кунак килгән кебек, аның бер үзенә самавыр куя, малайның сөйләгәннәрен рәхәтләнеп тыңлап утыра иде.

Ләкин болар барысы да әле соңрак булачак. Хәзергә без кунаклар кабул итеп бушый алмыйбыз. Әле берсе килә, әле икенчесе. Бөтен авыл булып бетте диярсең. Бер өем күчтәнәч җыелды. Олесь инде Банат җәеп биргән йомшак түшәккә чумып йоклый иде. Песи балабыз Лиска да үзенә урын тапкан — иң биек мендәр өстенә менеп бөгәрләнеп яткан. Миңа да аерым бер түшәк бирделәр. Бары тик Рекс кына идәндә ята. Ләкин аның моңа һич тә исе китми. Йоклый бирә шунда, ара-тирә аяклары гына селкенгәләп куя. Күрәсең, ул төшендә дә чабуын дәвам иттерәдер...

Г. ШӘРӘФЕТДИНОВ
тәрҗемәсе.

Дилә БУЛГАКОВА

Учаклар ягам боздан

Уралның бөркете үзең,
Киткәнсең салкын якка.
Урап кайт туган ягыңа —
Гөлләрең чәчәк ата.

Кышлары нинди сихри, ак,
Күзләрен миләш пешә.
Уралың чакыра сине:
Тауларда булдым кичә.

Мәхәббәтен өшеткән дә
Алып киткәнме бездән?
Урап кайт туган ягыңа:
Учаклар ягам боздан.

Имән

Син килергә вәгъдә бирмәдең,
Ә шулай да көтте имәнең.
Син онытма: имән бик горур —
Баскан килеш кенә ул торыр.
Каршы алыр килгән көзләрен,
Беләм еллар яфрак өзгәнен.
Ә шулай да имән бик горур,
Баскан килеш кенә ул корыр.

Тирәкләрдән оча ак мамык

(Җыр)

Аккан суга карап,
Толымнарын тарап,
Озатып калды ярдан талыбыз...
Бергә бәйләсәк тә,
Бергә бәйләнсәк тә,
Ялгыз гына акты салыбыз...

Сулар ярдан артты,
Еллар алга акты,
Салыбызны гына тапмадык...
Еллар шавын чорнап,
Яшьлек җырын җырлап,
Тирәкләрдән оча ак мамык.

Буләк

Буләк иттең миңа көмеш чылбыр:
Туңып калган алмаз ташы бар.
Кайчак яна яшен уты булып,
Кайчак күрәм: салкын бозлы кар.

Ярларыма дулкын кагылганда
Уеп ала йөрәк ярасын.
Тик белмәдем еллар чылбырында
Яшь тамчысы туңып каласын.

Тауда кызлар чәчкә җыйды,
Кояш сипте ал нурын.
Күтмәгәндә болыт чыгып,
Коеп китте яңгырын.

Әй кызлар йөгерә көлеп,
Чәчләре тәмам юеш.
Ә гөлләр кайта кәрзиндә
Күзләрен ачкан килеш.

Әнисә ТАҺИРОВА

Тере бизәкләр

Каелган шушы тастымал,
Әбием биргән бүләк,
Тере нур сибеп торгандай,
Андагы һәр гөл-бизәк.

Тамыр җәеп китәр төсле
Шул гөлләр учларымда.
Бизәк түгел, шигъри юллар
Тастымал очларында.

Илтә хыял дөньясына
Кызыл, зәңгәр җепләре...
Бу чигеш башкорт кызының
Иң матур өметләре.

Тастымал читен каймалый
Ал, яшел нәкышлары,
Болары яшь киленчәкнең
Уйлары, сагышлары.

Җемелдәшә ефәк чуклар,
Көмеш төс белән яна,
Нужа татыган җиңгәнең
Гүя күз яше тама...

Шушы бизәкләр артыннан
Чишмә тавышы булып,
Шундаен таныш саф бер моң
Чыңлый йөрәккә тулып.

Ышанмасаң

Ышанмасаң әгәр сөймә мине,
Ышанмаган сөймәс, сөелмәс,
Ышан миңа диеп горур башым
Ышанычың сорап иелмәс.

Ышанмаган — нурдан, җырдан мәхрүм,
Ышанмаган йөрәк — бәй-җепле.
Ышанганнар гына сүзсез сөя,
Ышанганнар гына бәхетле.

Фәния ЧАНЫШЕВА

Бала өчен...

Бар хәстәрем, бар хәсрәтем
Бала өчен..
Хөрмәтем дә, хезмәтем дә
Бала өчен.
Үкенүләр, үтенүләр
Бала өчен,
Тынгысыз көн, йокысыз төн
Бала өчен.
Утка, суга укталуым
Бала өчен.
Чыгар юлдан тукталуым
Бала өчен.
Таңнан әүвәл кайнар аш та
Бала өчен.
Тәгәрәгән кайнар яшь тә
Бала өчен.
Иртә-кичен йөрәк хисем
Бала өчен.
Барлык эшем, барлык көчем
Бала өчен.
Янам-түзәм, көям-кунәм
Бала өчен.
Горур башны түбән иям
Бала өчен.
Төнен якты таңнар көтәм
Бала өчен.
Күңелемдә җырлар йөртәм
Бала өчен.
Бала өчен...

Яшәреп чыкты да болыт
Таулар тирәләп кенә,
Күкрәде, яшьнәде, үзе —
Үтте сибәләп кенә.
Суга сусаган гөлләрне
Әллә күрмәде дәме?
Печән кибәр болыннарга
Коеп түгәдер әле.
Мәхәббәтем, көч-терәк бул,
Күтәр биеккә, үргә,
Адашкан болытлар кебек,
Кирәксез була күрмә.



Кайнар кояш кырлар иңен
Алтын нурдан киендерде,
Терекөмештәй кар сулары
Йөгереп-йөгереп юды җирне.

Юды үлән тамырларын.
Юлда яткан чуер ташны,
Тау битендә көнгә карап,
Умырзая күзен ачты.

Ерак кыйтгаларны гизеп,
Сагынып кайткан туган илне,
Иртән иртүк канат җилпеп,
Сыерчыгым телгә килде:


— Кошчыкларым, шатланыгыз,
Бу каенлы аланыбыз,
Чит якта да онытмагыз,
Шушы инде Ватаныбыз!

Кышын ап-ак кершән карлы,
Җәйләрендә гөл генә ул.
Яшәү биргән, канат куйган
Туган туфрак бер генә ул.

Озатып калдым. Башта ераклашты,
Аннан тынды синең адымнар.
Миңа тагын үткәннәрдә калды
Көннәр, төннәр, шатлыю-кайгылар.

Мин ялгызым. Тирә-ягым тып-тын.
Шом бар кебек мондый тынлыкта...
Искә төште саксыз әйткән сүзләр,
Юшкын салып үткән минутлар,

Әйтелмичә калган җылы сүзләр,
Кайчак җитми калган түземлек,
Үкенүләр, шомнар, моңнар аша
Күтәп алам сине өзелеп.



Сәрия **МӘҺДИЕВА**

Гармун моңнары

(Җыр)

Тәүге сөю хисләремне
Онытырлык түгел,
Өмет белән көтте һаман
Тынгысыз күңел.

Кайталмадың, калды бары
Таныш моңнарың,
Ялгызлыкта үтте инде
Гомер юлларым.

Күңелләрне тибрәлдерә
Гармун моңнары,
Хәтерләтә үткәннәрне —
Яшьлек елларын.

Гармуныңны дустың уйный,
Әйдә, уйнасын
Тик сөйгәне минем кебек
Ялгыз булмасын.

Язгы сагыну

(Җыр)

Язлар җитсен, гөлләр үссен өчен,
Шаулап аксын өчен елгалар;
Син бит бердән гүзәл гомереңне,
Тыныч булсын өчен дөньялар.

Еллар үтә, тагы язлар җитә,
Бар табигать гөлгә күмелә.
Онытылмас язгы сагыну булып,
Син яшисең минем күңелдә.

Виктор **АРШИНОВ** рәсемнәре.

Роберт **МИҢНУЛЛИН**

Кем улы мин?

Бабайның да
Улы мин.
Әбинең дә
Улы мин.
Әтинең дә
Улы мин.
Әнинең дә
Улы мин.
Апарның уң
Кулы мин.
Бабай кебек
Булырмын,
Әби кебек
Булырмын,
Әти кебек
Булырмын,
Әни кебек
Булырмын
Бернигә дә
Карамый.
Шулай булмый
Ярамый —
Соң бит инде
Олы мин,
Туган илнең
Улы мин!

Ничек уйлыйсыз?

Уйлыйм мин уйнаганда да,
Уйлыйм йоклаганда да.
Йокламыйча ятам, ләкин
Качып булмый анда да.

Төрле-төрле-төрле уйлар
Ала мине бөтереп.
Уйлыйм-уйлыйм-уйлыйм-уйлыйм...
Булмый уйлап бетереп.

Беләм инде, уйлануның
Сез дә кимен куймыйсыз.
Уйламый ярамыйдыр шул —
Ә сез ничек уйлыйсыз!

Саттар дәү үскән

Мин ник бәләкәй
Түгелдер инде!
Бәләкәй чакта
Күңелле иде.
Күтәреп кенә
Йөртә иделәр,
Борынымны да
Сөртә иделәр.
Алмаш та тилмәш
Сөя иделәр,
Саттар — зур малай,
Дия иделәр.
Вәт әйбәт иде
Бәләкәй чаклар,—
Ди әнисенә
Дүрт яшьлек Саттар.

Әйтмим берегезгә дә

Әни кайтып керүгә:
— Пыр тузган өй эче, — ди, —
Ах, ватылган тәлинкәм,
Кайсыгызның эше! — ди...

Тәлинкәне
Кем ватканны
Беләм бары мин генә.
Беләм дә...
Әйтмим генә.

Әйтмим аны әнигә дә,
Әйтмим аны сезгә дә.
Әйтмим булгач, әйтмим инде —
Әйтмим берегезгә дә.

Әгәр дә ул серне чишсәм,
Көлер идегез бугай,
Тәлинкәне мин ватканны
Белер идегез бугай.
Хәйләкәрләр!

КАРТ



Резеда ВӘЛИЕВА

Хикәя

Хәбир ӘХМӘТҖАНОВ рәсемнәре.

Галия әби белән Шаһидулла бабай арысландай өч малай һәм тыйнак кына, сылу гына бер кыз үстерделәр. Инде балалары башлы-күзле булып, төрлесе төрле якка таралып бетсәләр дә, кайсын кышка, кайсын көзгә, кайсыларын сабан туйларына каршы алып, аннары тагын кайтуларын көтеп, күңелле генә яши бирделәр.

Шаһидулла бабай яздан башлап кара көзгә кадәр өй артындагы алма бакчасын карый, бердәнбер аяклы маллары булган сыерлары тирәсендә мәш килә иде. Галия әби исә бакча җимешләреннән балаларына кагын, вареньесын әзерләп, чолан белән кар базы арасында килеп сарды, кыш көннәрендә, әле тегесен, әле монысын карап, өй эчендә кайнашты. Балалары аларны акчасыннан да, күчтәнәчләреннән дә өзмәделәр. Бигрәк тә зур гына бер урында эшләүче олы уллары Закирҗан ярдәмләште. Шулай итеп, Шаһидулла бабай картлыгыннан да, балаларының аерым яшәүләреннән дә артык зарланмыйча, булганына шөкер итеп, карчыгы белән чүкердәшеп кенә яшәп ятты. Балалары кайткан чакларда алты почмаклы матур йортлары гөр килеп тора иде. Җәй көне булса, бакчаларында, ишегалларында җыр, гармун тавышы тынмый, кыш көннәрендә исә ябык тәрәзәләр аша да моң саркып, тын авыл урамнары буйлап еракларга-еракларга ишетелә иде.

Яшь чакларында Шаһидулла бабай бик шәп гармунчы, Галия әби авылның беренче җырчысы булган дип сөйлиләр. Күрәсең, шуңадыр Шаһидулла бабай әле хәзер дә гармунны еш кына тоткалый. Андый минутларда Галия әби дә ничектер балкып, яктырып киткәндәй була.

Шулай гомер буе бик матур, бик тату яшәделәр алар. Галия әби, сабыр холыклы булгангамы, сәламәтлегеннән үзе бер дә зарланмый иде. Ә инде карты кәефсезләнебрәк китсә, угалап-сыйпап, ниндидер үләннәр эчертеп янында мәш килеп йөрер иде. Шундый чакта карчыгына карап, «үземнән калгач нишләр инде бичаракаем, гомер буе бер җан булып яшәдек шул», — дип үзәкләре өзелеп куя иде Шаһидулла бабайның.

Ләкин язмыш боларын үзенчә хәл итте.

Җәйге бер иртәдә, сыерларын көтүгә куып ишегалдына килеп керүгә, башындагы ак яулыгы белән йөзен каплап, баскычка кырын яткан карчыгын күреп Шаһидулла бабай әсселе-суыклы булып китте. Тез буыннарының калтыравын җиңә алмыйча, карчыгы янына килеп утырды да дерелдәгән кулы белән әкрен генә аның иңенә кагылды:

— Сиңа әйтәм, башың әйләнде мәллә?..

Карчыгы җавап бирмәде..

Шуннан соң ниләр булганы ачык кына исендә калмаган Шаһидулла бабайның. Врач килүен дә, үзенә укол кадауларын да, балалары кайтып төшүен дә авыр төш кебек кенә хәтерли ул. Ә менә кып-кызыл балчыклары белән ачылып яткан җир куенына Галиясен иңдерүләре бер генә минутка да онытылып торганы юк. Ничек итеп онытмак кирәк, өйдәге бөтен нәрсә: тәрәзә төбендәге гөлләр дә, мөгрәп йөргән коба сыер да, алмагачлар да, хәтта гомер буе икесенә чәй эчергән җиз самовар да аны юксыналар кебек.

Әтиләренең авыр хәлен күреп, уллары аны үзләре белән алып китәргә тырышып карадылар.


— Әнкәгезнең әзе дә суынып бетмәгән бит әле, ничек телегез бара? — дип кенә җавап бирде ул, әрнеп.

Әниләрен җирләп өч көн үткәч, уллары, әтиләре янында яшь баласы белән сеңелләрен калдырып, өйләренә кайтып киттеләр...

Авыр хәсрәт эчендә елдан артык гомер узды. Көз көне, ниһаять, Закирҗаны Шаһидулла бабайны үзләренә барырга күндерә алды. Сыерны саттылар, йортның тәрәзәләрен кадакладылар...

Өч атна инде менә Шаһидулла бабай Казан каласындагы зур бер йортның дүрт бүлмәле квартирында яши. Улы белән килене эштән соң гына кайталар, бердәнбер уллары Альберт көне буе үз эшләре белән мәш килә, әле дәрес әзерли, әле телевизор карый, алай да булмаса, иптәш малайлары белән

ЛАР КҮҢЕЛЕ ПЫЯЛА



бергәләп магнитофон тыңлый. Озын буйлы, җитү чәчле, сөлектәй сылу оныгына карый да хәйран кала Шаһидулла бабай: ни арада үсеп җитте әле ул? Кайчан гына бот буе бала иде. Авылга кайтты исә, алма бакчасында куыш корып, бу минем штаб дип, шунда үзенчә туплар куеп, алардан аткан булып мәш килә торган иде. Бик тә тере, бик тә зиһенле бала иде. Тик киленнәре Даниянең аңа «Алька», «Алечка» дип, ир балага һич тә ябышмый торган исемнәр белән дәшүе, оныкларының үз телебездә сөйләшмәве генә күңелләрен рәнҗетә иде. Дәү әниләре, мәрхүмә, бакчада кайнашкан оныгын ашарга керергә чакырып-чакырып та тегесе һаман кермәгәч, тәмам гаҗиз булып: «Әй, ходаем, үз балаң белән икең ике телдә сөйләшкәч, ул сине ничек якын итсен!» — дип, бөтен йөрәге белән сыкранып ала иде. Әйе, якын итеп бетерми шул оныклары, менә хәзер, көннәр буе ялгызы утырган чагында: «Нихәл, дәү әтием?!» — дип бер генә эндәшсә дә яралы күңеленә җиңелрәк булып китәр иде дә бит, юк шул, эндәшми. Алай гына да түгел, оныгы аның барлыгын да сизмәгәндәй итенә, ә килгән дуслары күп вакыт исәнләшергә дә оныталар. Яшьләрнең мондый кыланышлары Шаһидулла бабайны бик тә рәнҗетә, шуңа күрә ул алар күзеннән кая да булса читкәрәк качарга тырыша иде.

Бер көнне улы Закирҗан эштән иртәрәк кайтты. Кайтып керүгә үк тантаналы бер төстә куанычлы хәбәр әйтте: аны, илле яшь тулу уңае белән, озак еллар намуслы хезмәт итүе өчен, орден белән бүләкләгәннәр, кичен кунаклар да киләсе икән...

Кичке сәгать җиде тулганда балкып торган зал уртасындагы зур өстәл кунаклар каршыларга әзер иде инде.

Кичә күңелле генә барды. Уен-көлке, тантана белән вакыт узганы сизелми дә калды. Шаһидулла бабай күп көннәрдән соң беренче тапкыр авыр кайгысыннан айнып киткәндәй булды, кешеләр белән бергә ашады-эчте, балаларының куанычы белән куанып, күңелле генә елмаеп утырды. Бераз кызып алгач, кунаклар җырлаша, биешә башладылар, Шаһидулла бабай да әкрен генә урыныннан күтәрелде дә, күрше бүлмәгә кереп, гармунын кулына алды...

Шул кадәр бирелеп уйнады ул, бөтен күңеле, бөтен йөрәге белән сызланып: «Галиябану, сылуым иркәм, шул кадәрле сагындым»... — дип сузган чакларында күзләренә тулган яшьләрен башкалар күрмәсен өчен, гармунына сыена төшеп, башын түбән иде. Ләкин кечкенә бүлмәгә җыелып өлгергән кунаклар үзләре дә аннан ким дулкынланмаганнар иде күрәсең, барысы да моң иркенә бирелеп, башларын иеп тынып калганнар... Кинәт тавыш яңгырады:

— Әй, ниткән меланхолия бу?! Ну-ка, дед, хәзер үк туктат!

Әллә кечкенә бу бүлмәдә агылган көй артык нечкә, моңлы булганга, бу яшь тавыш шул кадәр дорфа ишетелде ки, тыңлаучылар, тетрәнеп китеп, башларын күтәрделәр.

Алар алдында Закирҗанның бердәнбер улы Альберт басып тора иде. Ишек турындарак ваемсыз гына елмаеп тагын ике-өч егет туктап калганнар.

Шаһидулла бабай башын күтәрде, оныгының тәкәббер карашы белән очрашып, сүзләренең мәгънәсе зиһененә барып җиткәч, үзе сузган гармун күреген дә җыеп алалмаслык бер хәлдә урыныннан кузгалды. Тик гармун гына, өзелгән моңны кызганып уфтангандай, авыр сыкранып куйды...

Стеналарны дерелдәтерлек куәт белән үкереп-чинап җибәргән магнитофон тавышыннан кунаклар исләренә килеп, уянып киткәндәй булдылар. Бераз гына вакытка онытылып торган авыр кайгыларын янә җилкәсенә җыеп салгандай, бөрешебрәк калган Шаһидулла бабай иелгән башын күтәрмәде. Аңа елышыбрак баскан кунаклар да сүзсез калганнар. Бүлмәдә колак тондыргыч музыка тавышы гына ярсыганнан-ярсый бара иде.



Рәйсә ЮСУПОВА

Ә ТЕГЕ ЧАКТА...

Ул ирен көтте. Яратып, сагынып түгел, курка-курка көтте. Менә-менә кайтып керер дә, гадәттәгечә, сагындым сине, Халисәкәй, дип муенына сарылыр, ә син... син сагындыңмы соң үзеңнең Вәкилеңне дияр төсле тоелды. Ә Халисә аның иркәләвеннән куырылып төшәр, олы итеп алдашмас өчен я эндәшми калыр, яки «ә-һе», дияргә мәҗбүр булыр...

Юк, ишек әле ачылмады. Бусагада, авызын ерып, әлегә Вәкил басып тормый. Әмма, кайтмый торуы хәерлерәк булса да, кайтыр инде, командировка срогы бетте шул.

Кинәт Халисәгә салкын булып китте. Күңелсез уйларыннан бөрешеп, кечерәеп калгандай булды ул. Йокы бүлмәсенә үтеп, зур көзге каршына басты да җитез хәрәкәтләр белән чәчен тарый башлады. Йөрәкнең мондый сыкрануын ни беләндер басарга кирәк иЧ! Дулкынланып торган чем-кара чәчләре иңнәренә таралды. Көзгедәге шәүләсенә Халисә күз кысып алды: бу чәчләр, бу зур коңгырт күзләр, йөзгә зәңгәрсу күләгә бирүче бу озын керфекләр, төз борын, бит алмалары алсуланып торган озынча йөз — шөкер янәсе! Маңгае өстендә генә өч бөртек ак чәч күреп, Халисәнең тарак тоткан кулы кинәт туктап калды. Ходаем, әле утыз яше дә тулмаган хатынның чәче агара түгелме?

Зың-зың килеп, звонок шалтырады. Авырлык белән генә Халисә ачкычны борды. Бусагада, киң елмаеп, Вәкил тора иде. Гадәттәгечә ул хатынына омтылды:

— Шундый сагындым! Тагын бер генә көн... юк, тагын бер генә сәгать күрмәсәм дә — түзә алмас идем. Яратам сине, Халисәкәй, өзелеп яратам. — Вәкил хатынын читкәрәк этәрде дә, аның күзләренә текәлде. — Мондый гүзәл хатынымны яратмаслыкмы соң?

Халисәнең йөрәге кысылды. Мин шул ук Халисә иЧ, ә теге чакта... Теге чакта яшьрәк тә, матуррак та идем әле диясе, кычкырасы килде. Әмма эндәшмәде. Бу юлы да аны акылы тотып калды.

— Әти кайтты... Әти! — Игезәкләре Дилбәр белән Динә балалар бүлмәсеннән чыгып, әтиләренә сарылдылар. Вәкил тагын да балкып, кызларын күккә күтәрде.

Дөньялар түгәрәк кебек иде. Тик Халисәнең кысылган иреннәре очына гына әйтелмәгән һәм тәгаен бер кайчан да әйтелмәячәк сүзләр эленде: «Ә теге чакта...»

•

Шомырт чәчәк аткан чак иде. Урта мәктәпне тәмамларга да санаулы гына көннәр калды. Соңгы, чыгарылыш имтиханнарына әзерләнеп утыручы Халисәнең инди бүген үк, менә хәзер үк, саумы, киләчәк! дип бөтен дөньяга аваз саласы килә... Кызның уйларын, укуын бүлеп, ишек шакыйлар. Авылда шакып керү гадәте юк иЧ — кайсы кылана икән? Халисә ишеккә ташлана һәм... аптырап туктап кала. Бусагада, матур елмаеп, моряк киеменнән озын буйлы егет тора.

— Исәнмесез! — чәчләренә шомырт чәчәге кыстырган ялан аяклы кыздан күзен алмый егет.

— Мин сезне беләм бит! — ди ул.

— Соң?

— Мин сезне беләм бит!

— Бик яхшы. Алай булгач, узыгыз соң?!

— Шулай да мин сезне беләм, — ди егет ни өчендер шатланып. — Моннан өч ел элек мин сезне мәктәп ишегалдында күрдем. Армиягә китешли укытучыларым белән саубуллашыйм дип кергән идем. Кызык. Армиядән кайтышлый да сезне очраттым. Терпеле елгасы артында гына безнең авыл. Ә сезнең өйгә очраклы әләгүем. Юл өстендә бит! Су эчеп чыгыйм дип кергән идем.

— Нишләп бусагада торасыз? Үтегез. Армиядән кайтучы моряк абыйга суның чиләге дә җәл түгел.

— Вәкил исемле мин. Ә сез?

— Халисә...

Алар көн саен очраштылар. Төн караңгылыгы да, йомшак җил дә, тын елга да, бөдрә таллар, өянкеләр, зифа буйлы каеннар да серләшүләренә шаһит иде. Төн кошлары исә аларга мәхәббәт җыры җырладылар, таң йолдызлары көнләшә-көнләшә бәхет теләделәр.

— Халисә!?

— Әү, Вәкил абый?

— Өйләнешик без... Сабан туена шаулатып туй ясыйк. Ә, Халисә?

— Ни сөйлисез, Вәкил абый?!. Казанга китеп укырга керү турында әле хәзер генә сөйләштек ләбаса...

Халисә медицина, Вәкил авиация институтында укый башладылар. Очрашулар сирәкләнде. «Ял көннәрендә генә күрешик, Вәкил абый, стипендиясез каласы килми», — диде кыз катгый рәвештә.

Ә яз-җәй көннәрен алар тагын бергә үткәрделәр: сабан тургайлары җырын, күккүк тавышын тыңларга авылга кайттылар, колхоз болынында печән җыйдылар. Терпеле елгасының икесе ике ярында су коендылар.

Шулай ике көз, ике кыш, ике яз үткән иде. Вәкил кинәт үзгәреп китте, боекты.

— Җитте, Халисәкәй, җитте, — диде ул, ниһаять, ярым пышылдап, ялварып. — Башкача синсез яши алмыйм. Яратам бит мин сине, яратам!

Сабан туенда ике авылны шаулатып, туй үтте...

Бергә тора башлауның беренче көннәре матур иде. Шәһәр читендәге агач өйнең кечкенә генә бүлмәсендә сөю яшәде, шатлык яшәде, бәхет яшәде.

Ә Яңа ел кичәсендә:

— Гүзәлемне котлыйм! Мәхәббәтемне котлыйм! Саф ярату өчен эчик, Халисәкәй, шушы шәрабтай сафы өчен, — ди Вәкил.

Шампан шәрабе тулы бокалын күтәрми Халисә. Оялып кына Вәкил беләгенә кагыла.

— Син эч, Вәкил, икебез өчен дә эч. Миңа ярамый. Бәләкәебез булачак.

— Ничек?.. Нәрсә сөйлисең син?

— Соң... мәхәббәтебезнең җимеше.

— Ә уку? Укуыбыз нишли?

— Укырбыз, Вәкил. Кешеләр икешәр бала белән дә укыйлар әле.

— Ә мин... минем хатыным акыллы дип йөрим тагын.

— Их, син! Яңа ел кичәсендә шатландырыйм дигән идем...

Вәкил үз дигәнен эшли — больницадан бәбәйне балалар йортына озаталар.

«Озын» тәнәфесләрдә шәһәрнең бер башыннан икенче башына Халисә бала имезергә йөгерә. Лекцияләрдән соң тагын шунда чаба. Сигезләргә, тугызларга хәтле утыра да, елый-елый, күкрәгеннән аерып, нарасыен тәрбиячеләргә суза.

— Йөрисең шунда... Вакытында ашарга пешерми, иреңне карамый, — дип каршылый аны Вәкил.

Матур һәм авыр студент еллары да артта кала. Аларның икесен дә шәһәрдә эшкә билгелиләр. Вәкил Фазлыев бер идарәдә, Халисә Фазлыева исә бер заводның терапевт кабинетында эшли башлыйлар. Хәзер инде балабыз яныбызда булыр, дип сөенә ана. Әмма...

— Ашыкмыйк, Халисә. Бераз аякка басыйк... Бала инде андагы режимга күнеккән. Бераз гына үзебез өчен дә яшик, акча җыйныйк. Аннан... күз күрер аннан.

Иркәләп тә, ачуланып та Халисәне бу юлы да күндерә Вәкил. Тик араларына ниндидер салкынлык үтә. Вәкил эштән еш кына вакытында кайтмый башлый. Хатынының да бик күп җитешсезлекләре бар икән ләбаса. Ничек элегрәк күрмәгән ул — сукыр булганмы, югыйсә. Әнә фәлән кешенең хатыны уңган ичмасам. Ул да врач икән. Ике ставкага эшли, ди. Суыткыч алганнар, инде машина алырга җыеналар бугай.

Шуңа охшашлы сүзләрне Халисә еш ишетә. Һәм ул да ике җирдә эшли башлый. Иртә китә, соң кайта. Арып кайта. Шулай да Вәкиле өчен тәмле-тәмле ашлар әзерләргә вакыт таба ул. Тик ике эш арасында сабые янына йөгереп, Вәкиле өчен эшләп, алар өчен яшәп үзе турында оныта Халисә. Бөтенләй оныта. Хәзер, үзе турында уйларга вакыты да булмый аның.

Шундый көннәрнең берсендә, юарга кулъяулыгын алганда, Вәкил кесәсеннән ике билет төшә. Театр билетлары. Иртәгесен Халисәгә иренең эш урыныннан шалтыраталар.

— Сезнең ирегез — бүлек мөдире Вәкил Фазлыев — үзенең хезмәткәре Луизаның башын әйләндерә. Менә өч тапкыр инде аны үзе белән Мәскәүгә командировкага алып барды. Ә кичә аларны театрда күргәннәр, — ди тавыш.

Ышанмый Халисә.

Август ахырларында тагын шалтыраталар:

— Сезнең ирегез 27 сеннән, ягъни иртәгә ялга чыга. Луиза белән Сочига китәчәкләр!

Яшен тизлеге белән Халисә миендә уйлар алышына.

Әйе. Сочига китәчәк Вәкиле. Юл капчыгына кирәк-яракларын тутырып куйды инде Халисә. Әйе. Бераз ял итсен, диңгез һавасы суласын Вәкиле. Ә Халисә?.. Ике җирдән дә бер үк вакытта ял бирмиләр шул. Аннан мотоцикл өчен алып торган бурычны да түлисе бар. Тукта-тукта! Анысы — нинди Луиза тагын? Булмаганны...

— Ал-ло! Ал-ло!..

Телефон җавап бирмәде. Трубканы куйганнар иде инде.

Халисә ул идарәнең кадрлар бүлегенә шалтыратып, Луизаның кайда торганлыгын белеште һәм, эшеннән сорап, кыз торган тулай торакка юнәлде.

Сары чәчле, озын буйлы, таза гәүдәле Луиза белән сөйләшүе авыр, бик авыр иде.



И. ИШМӨХӘММӘТОВ фотосы.

— Сеңлем, юкка рәнҗетсәм, гафу итәрсез, зинһар,— диде Халисә бик кыенсынып.— Тик сөйләшмичә ярамас. Соң булуы бар. Ганлә-бездә нидер булды, сеңлем, Вәкил бик үзгәрде. Әллә аның күзе сезгә төшкәнме? Зинһар, гафу итә күрегез.

Луиза кызарып китте.

— Юк-юк, апа, сез миннән гафу үтенмәгез. Үзегез мине гафу итегез. Чөнки мин сезне бөтенләй икенче кеше итеп белә идем. Тормыштан, культурадан артта калган бер хатын итеп. Гафу итегез, миңа сезне шулай әшәке итеп кат-кат сөйләде «ул». Мәхәббәт татымавыннан, аңа сусап яшәвеннән бик еш зарланды. Ә мин ышанган идем.

— Үскәнкәем...

— Юк-юк, апа, борчылмагыз, әле соң түгел. Арабызда берни дә булганы юк, — диде Луиза тагын кызарып.

Халисә җиңел сулап куйды.

— Алайса, минем киңәшемне дә тыңлагыз әле, сеңлем.— Ул, газапланып, кирәкле сүзләр эзләде.— Мин бик-бик яратам аны. Яратышып өйләнештек. Хәзер без өчәү инде. Улыбызга дүртенче яшь. Әти ул безнең. Ә сез, сеңлем, бала күтәреп, ялгыз калуны күзаллыйсызмы? Сез яшь әле, үз бәхетегезне табарсыз. Калдырыгыз аны, сеңлем, зинһар калдырыгыз.

— Ни сөйлисез сез, апа?! Мин бит боларның берсен дә белми идем. Сезнең яманатыгызны сатып, кызгандырып алдаган ул мине. Алдаган! Арабызны өзәчәкмен, апа. Бүген үк. Зинһар, тыныч булыгыз!..

Икенче көнне Вәкиле Сочига китте. Луиза белән. «Акыллы кызга охшаган, Сочида аңлашырлар, шәт», дип юатты үзен Халисә.

Әмма Вәкил Халисә янына кабат кайтмады. Бары китапларын, киемнәрен алырга гына кереп чыкты.

— Тормыштагы иң олы ялгышуым минем сиңа өйләнүем булган. Бу хатаны вакытында төзәтүем — барыбыз өчен дә яхшы булачак...

Ашыга-ашыга чемодан җыйганда әйткән соңгы сүзләре шул булды.

Халисә өнсез калды. Авыз ачып әйтерлек сүз тапмады. Тез буыннарының хәле бетеп, ишек яңагына сөялде.

Чемоданын Халисә аякларына бәрә-бәрә, ашыгып чыгып китте Вәкил. «Китте Вәкил»... «Юк Вәкил»... «Ниндидер кара көч тартып алды Вәкилне»...

— Ходаем, ниләр генә булды соң сезгә?! Пар күгәрченнәр кебек яши идегез бит. Күз генә тигәндер. Шулайдыр,— дип өй хуҗасы Мөкаррәмә апаның сөйләнә-сөйләнә су эчерүеннән Халисә аңына килде. «Вәкил...» Аның беренче уе һәм бердәнбер уе шул иде...

Көннәр, аһ, әкрен үттеләр. Ә төннәре газаплы иде, караңгы иде.

Эшкә барышлый Халисә я кешеләргә бәрелеп үтте, хәтта бишәр катлы йортка төртелеп, туктап калгалады. «Ходаем, Вәкиле бик интегеп яшәми микән? Вакытында кайнар аш ашаса ярый ла соң...», «Луизасы бик горурга охшаган, ярый ла бик тилмертеп яшәтмәсә Вәкилен...» Яраткан йөрәк шулай уйлады.

Айлар үтте. Халисә дә аек акыл аша дөньяга карарлык хәлгә килде.

Заводтан бирелгән кечкенә бүлмәсенә улы Тәүфыйкны да алып кайтты.

— Хәзер беркайчан да аерылышмабыз, улым, төнлә дә син минем белән йокларсың, бер кроватта,— диде ул шатланып.

— Әни,— ди бала беркөнне,— Марат әнә этисе белән су коенган. Ә минем этием кая соң?

— Бар, улым, синең этиең, бар. Ерак командировкада ул. Ә Казанкага су коенырга ял көнне икәү төшәрбез, яме?

Бала белән ана эссе көнне кызындылар, чәчрәтә-чәчрәтә су коендылар да, киемнәре янына йөгерделәр. Кемнеңдер карашын тоеп, Халисә туктап калды. Бу — «ул» иде. Луизасы агачлар ышыгында тора — ана булырга җыена, ахрысы.

— Әйдә, улым, тизрәк киеник тә, тизрәк китик моннан. Паркка барырбыз, таганда атынырбыз,— диде Халисә малаеның кулын шатырдатып кысып.

Ә кичен звонок шалтырады. Ишек төбендә Вәкил тора иде. Башы иелгән, күзләре дә түбән карыйлар.

— Әгәр син рөхсәт итсәң, мин бераз гына улым белән сөйләшеп утырыр идем,— диде ул мескен кыяфәттә.

Эндәшмәде Халисә. Юк, ул аны көтмәгән иде.

— Менә әниебез рөхсәт итсә, озакламый мин дә кайтырмын, улым.— Вәкил кыяр-кыймас кына Халисәгә карап ала. Эндәшмәүне ризалык билгесе дип белеп ахры, кыюлана төшә.— Мин сиңа велосипед та алып бирермен, улым...

Тәүфыйк этисенә шикләнеп карап торды да, әнисенә борылды: чын әйттеме ул янәсе.

Бу юлы да эндәшмәде Халисә. Бала белән атаның сөйләшүенә кысылмаска булды. Әмма үз сүзен әйтер әле ул, әйтер.

Икенче килүендә исә ата кыюлана төшкән иде. Тәүфыйк та алай шикләнмәде, читенсенмәде.

— Әнием янына абыйлар киләме, улым? — Ата әрсезләнгәннән-әрсезләнә бара иде.— Килмиләрме? Бик шәп. Килсәләр, этигә әйтәм, диең, куып чыгар, улым. Молодец булырсың.

«Шушы кешеме соң аның Вәкиле? Шушы кешеме аның олы мәхәббәте?»

Вәкил килгән саен кыюлыгын арттырды

— Шимбә көнне кайтырга уйлыйм мин. Бөтенләйгә,— диде ул, ниһаять, бер килүендә.

— Кем янына?

— Ничек инде ул «кем янына»? Улым янына. Синең янга — законлы хатыным янына.

— Ник?

— Синсез, Халисәкәй, һәм улымнан башка яши алмыйм икән мин. Шушы ел эчендә сиңа булган мәхәббәтемнең олылыгын, сафлыгын аңладым. Китеп торуым да болай гына иде бит. Чынлап торып уйлаган булсам, сине аерган булыр идем. Минем законлы хатыным бер генә — ул син.

«Ходаем, ни сөйли бит, ни?! Миңа карата мәхәббәтенең сафлыгын тикшерү өчен башкага өйләнеп торган булып чыга түгелме?»

— Бу уеңны Луиза беләме?

— Исемен дә ишетәсем килми, Халисәкәй. Зинһар, бу турыда сөйләшмик.

— Шулай да минем беләсем килә: ник ташларга җыенасың син Луизаны?

— ...

— Җавап көтәм.

— Ник кирәк ул миңа, ник? Дорфа. Ашарга да юньләп пешерә белми. Ул үзе ташланды минем муенга, үзе. Син аның белән сөйләшкән булгансың, сиңа вәгъдә биргән, ә үзе котән минем белән Сочига китеп барды. Җитте! Булды! Күрәсем дә килми.

«Кыерсытылган кеше кебек сөйләшә. Әйтерсең лә ниндидер изгелек эшләгән. Һәм аның изгелеген һаман аңламыйлар».

— Балагыз булырга тора икән.

— Булса соң? Табар да, карар да. Кем кушкан аңа. Ә син, нәрсә, җәллисең мени? Ә ул җәлләдеме сине?

«Юк. Ул мине җәлләмәде».

— Луиза ана булырга җыена. Күңеленең иң нечкәргән чагы. Ә син — Луизаның ире, туачак баланың атасы — хатыныңны больницага илтергә һәм аннан каршы алырга тиешсең! Мин моны врач буларак әйтәм.

— Их, син! Изге җан...

Тәүфыйк еш кына этисенә сарыла. Үзкәләрне өзеп, китмә инде, эти, китмә, ди.

Мондый чакларда исә Халисә үз сүзләрен ишеткәндәй була: «Ә сез, сеңлем, бала күтәреп ялгыз калуны күзаллыйсызмы?» Бәлки... юк-юк! Моңа бармаячак Халисә. Ата кулы, ата иркәләве күрми үз сабыеның үсүе дә бик җиткән.

Тагын килде Вәкил.

— Булды, Халисәкәй, син кушканнарның барысын да эшләдем. Баласы белән Луизаны алып кайтып куйдым.

«Баласы».. «Алып кайтып куйдым»... Җиңүчемени. Менә хәзер өзәргә кирәк. Бөтенләйгә. Юкса, ул шулай гомер буе ике арада йөрисчәк.

— Котлыйм! Тагын эти булгансың.

Вәкил куркып китте. Халисәдәге салкынлык, битарафлык кинәт аны өшетеп җибәрде.

— Алай карама миңа, Халисәкәй! Үтенәм синнән. Мин синең җылы карашыңа мохтаҗ. Назлы карашыңны, сөю ташып торган кара-

(Ахыры 24 биттә.)



ТЕШ СЫЗЛАВЫ

Рәбига апаның бүген кәефе юк. Кич белән фермадан кайтып, өй эшләрен дә тиз генә тәмамлап ашарга утырган иде. Авызына кайнар шулпа кабу белән яңагы чатнап, ашын да йота алмый өстәл артыннан ук чыгып китте. Электән дә аның беренче азау теше кайвакыт я салкын су, я татлы әйбер тисә, азрак сыкрап куя торган иде. Ә менә бу юлы инде, элекке сыман гына түгел, өздерәп сызлый башлады. Тешендә зур, тирән куыш барлыгын белми иде шул әле.

«Соң инде врачларын да әйтер идем. Елына берәр мәртәбә генә булса да безгә килеп, ферма эшчеләренең, сыер савучыларның чирле тешләрен ямап, үзләре әйткәндәй, кариесларга пломба салып китсәләр, нинди яхшы булыр иде. Теш врачлары өчен махсус автобус та бар диләр. Анда чын-чыннан врач эшләрлек кабинет ясалган, имеш. Димәк, кирәк-ярак әйберләре дә үзләре белән инде аларның. Ләкин кайда икән соң андый автобус-стоматология кабинеты? Нишләп безгә бер дә күрсәтмиләр икән соң аны?!»

Тәмам җәфаланып, икенче йокысыз төнне озатып, таңны каршылаганда Рәбига апаның авыз ачып сүз әйтер хәле дә калмаган иде. Иртә белән ашамый-эчми генә, үз урынына башка берәүне калдырып, районга китеп барды.

Теш врачы креслосына кереп утырган вакытта Рәбига апа өстәге тешләренең кайсы авыртканын аерып әйтә алмый иде инде. Аларның барысы да сызлый кебек. Врач игътибар белән Рәбига апаның һәммә тешен карап чыкты. Сызлаганы берәү иде. Аны чистартып, камфара мае белән мышьяклы паста салды. Аннары, 24 сәгать үткәч, ягъни иртәгә, янә 11 сәгать 20 минутта килергә «кабатлау» талоны бирде...

Врач янынннан чыкканда аның хәле беркадәр әйбәтләнгән иде. Үзе күбек ерак авыллардан килгән кешеләр белән сөйләшкәләгән арада сәгать көндезге ике тулды. Ә очраклы транспорт белән өйгә кайтып кергәндә кич якынлашкан иде инде.

Иртәгесен доктор аны елмаеп каршылады. Ничек кайтып җитүе, ничек йоклавы турында төпченде... Кичә салган мышьяклы мамыкны алып ташлаган ва-



«Кабактан нинди ашлар әзерләп була?

Гөлсара ХАРИСОВА. Казан».

Кабак кыйммәтле ризык. Ул шикәргә бай. Кабакта крахмал күп, C, B_1, B_2, E, P, P_1 витаминнары һәм каротин бар. Кабакта шулай ук калий, кальций, магний тозлары, тимер, бакыр, кобальт барлыгы беленде. Аңарда организмнан холестеринны куучы пектин дигән матдә күп, шуңа күрә кабак атеросклероздан бик файдалы, бөер, бавыр йөрәк һәм кан тамырлары авырулары белән чирле кешеләргә врачлар кабак ашлары ашарга тәкъдим итәләр.

ПАРЛАНДЫРЫП ПЕШЕРЕЛГӘН КАБАК

Кабакны әрчеп турагыз. Аны эмальле табага яки кастрюльга салыгыз, бераз гына су өстәгез, тоз сибегез дә, өстен каплап сүрән ут өстенә куегыз. Кабак парланып пешсен. Табага су урынына 1-2 кашык сары май салсаң тагын да әйбәтрәк.

Шулай пешерелгән кабакка салкын сөт яки сөт өсте салырга, мичтә пешерелгән салкын алма яки консервланган алма, яңа өлгергән җиләк өстәргә мөмкин. Аннары шикәр комы сибелә.

КАБАКЛЫ ТАРЫ БОТКАСЫ

Кабакны әрчегез, турагыз, аннары 5-6 минут сөттә пешерегез. Тары ярмасын әйбәтләп юыгыз, кайнар су белән парлагыз. Аны сөттә пешкән кабак өстенә салыгыз, тоз, шикәр өстәгез. Өстен каплап ботканы сүрән ут өстенә куеп 20 минут чамасы пешерегез. Ботка таралып тора торган булсын өчен болгатмый гына пешерегез. Аннары ботканы 20 минут чамасы бик үк кызу булмаган духовкага куеп торыгыз. Ботканы ак май белән ашыйлар.

500 г кабакка 2,5 стакан сөт, 1 стакан ярма, 1 аш кашыгы шикәр комы, май һәм тәменчә тоз салына.

БЕЛЕН ОНЫННАН КАБАКЛЫ КОЙМАК

Кабакны кисәкләргә турап мичкә куеп пешерегез. Белен оныннан коймак камыры изегез. Шуңа кабакны салыгыз, тәменчә тозлагыз, шикәр комы, изелгән йомырка өстәп камырны әйбәтләп болгатыгыз да коймакны пешерә башлагыз. Коймакны каймак, вареньe, консервланган җиләк-җимеш яки куертылган сөт белән ашыйлар.

1 кг кабакка 3 стакан белен оны, 2,5 стакан сөт, 2 йомырка, 1 аш кашыгы шикәр комы алына.

КАБАК БӨККӘНЕ

Кабакны әрчеп, вак кына итеп турагыз. Тары ярмасын бик әйбәтләп юыгыз, кайнар су белән парлагыз. Ярманы кабак өстенә салып болгатыгыз, тәменчә тоз, шикәр комы сибегез, йомырка сытып әйбәтләп болгатыгыз. Шушы әзер әчлекне түгәрәкләп җәелгән камыр өстенә салып бөккән ясагыз. Кызу духовкада бөккән ярты сәгать чамасы вакытта пешеп җитә. Бөккәнне кайнар көе урталайга ярып эретелгән ак май сибеп ашыйлар.

Эчлеккә 1 кг кабак, 1 стакан ярма, 1 данә йомырка, тәменчә тоз, шикәр алына.

КАБАКЛЫ ЭРЕМЧЕК ТӘБӘСЕ

Кабакны парландырып пешерегез. Манный ярмасын сөттә чылатыгыз, эремчекне иттарткычтан үткәрегез. Йомырканы шикәр комы белән изегез. Шуларның барысын бергә кушыгыз, каймак, эретелгән ак май, ванилин һәм тоз сибеп болгатыгыз. Каймак куелыгында масса барлыкка килер, куерак булса, сөт өстәгез. Шуны формага салып, духовкада пешерегез.

500 г кабака 400 г эремчек, 4 аш кашыгы манный ярмасы, 1 стакан сөт, 3 йомырка, ярты стакан шикәр комы, 100 г акмай, тәменчә ванилин һәм тоз салына.

«Балаларым шашлык ярата, аны авыл җирендә ничек пешерергә?

Римма СӘЙФУЛЛИНА. Башкортстанның Авыргазы районы».

Сарык итенең сөяксез җирен алып 30-40 ар грамм итеп кисәкләргә турагыз, һәр кисәкне аерым алып бераз төеп йомшартыгыз, тәменчә тоз, борыч сибегез, вак кына туралган суган өстәгез, бераз аш серкәсе сибеп барысын бергә болгатыгыз да 3-4 сәгать салкын урынга куеп торыгыз, маринадлансын.

Аннары ит кисәкләрен агач яки тимерчыбык таякларга тезеп әзер булганчы табада майда кыздырыгыз.

Шашлыкны таралып тора торган дөге боткасы белән бирәләр. Дөгегә эретелгән ак май сибәләр, шашлык өстенә боҗралап турап кыздырылган суган өстиләр, янына маринадланган кыяр яки помидор куялар.

«Журналның ноябрь санын алдым. Тышлыктагы фотода тәлинкәгә өелгән

кытта Рәбига апа доктор белән ачылып сөйләшә, сораулар яудыра башлады.

— Теш нидән авырта?

— Кариес нәрсә ул?

— Авылларга килеп теш дәвалау өчен стоматологик кабинетлы махсус автобуслар да бар диләр, хакмы?

Рәбига апа икенче көнендә район больницасыннан дәваланып кайтып җиткәндә, үз урынына калдырган кыз кичке савуны тәгәлләп, ферма мөдиренә сөтне тапшырып бетерә иде инде. Үзләренең Рәбига апаларын ике көн югалтып торган сыерлар сөтне дә азрак биргән булып чыкты. Иртәнге савуда — 20, көндезге савуда — 20, кичке савуда 40 литр сөт ким биргәннәр. Бу теш авыртуның бәласе икән. Бер тәүлек эчендә 20 сыердан 80 литр сөт ким ал, имеш!

«Юк, болай ярамый! — диде Рәбига апа. Бүген үк идарәгә барып, эчемдә кайнаган моң-зарларымны җитәкчеләргә сөйләп бирим әле. Кирәк икән, утырышка куйсыннар. Әмма ләкин стоматологны колхозга чакырырга кирәк. Бөтен авыл халкын тикшереп, авыру тешләрне бирәдә дәвыласыннар».

Асылгәрәй ЯПЕЕВ,
Казан дәүләт медицина институты, стоматология факультетының терапия кафедрасы доценты.

Редакциядән. Тешне саклау һәм дәвалау эшләренең безнең республикада ничек торышын белү өчен ТАССР сәламәтлек саклау министры урынбасары Фәрит иптәш Фаткуллинга мөрәҗәгать иткән идек. Ул безгә соңгы елларда тешне саклау һәм дәвалау өчен мөмкинлекләрнең шактый артуы турында сөйләде. Узган ике елда гына да республикабызда 1 стоматология поликлиникасы, 16 теш дәвалау бүлеге һәм кабинетлары эшли башлаган. Күчеп эшләүче теш кабинетлары чептәре дә киңәйгән. Бөтен аппаратлары, җиһазлары белән килеп, теш врачлары, әйтик, унар көн, икешәр атна мәктәпләрдә булалар һәм барлык балаларның тешен тикшерәләр, дәвалыйлар. Мондый кабинетлар предприятиеләрдә, профтехучилищеларда, балалар бакчаларында бик еш булалар. Әлмәт, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләре кешеләренә исә теш дәвалау аппаратлары белән җиһазландырылган махсус автобуслар да хезмәт күрсәтә.

Авыл кешеләрен дәвалау да җайга салына. Соңгы ике ел эчендә 12 авылда теш дәвалау кабинетлары эшли башлаган. Колхоз үзәкләрендә урнашкан бу кабинетлар якын-тирәдәге авыл кешеләренең дә тешләрен даими рәвештә тикшереп торалар, дәвалыйлар. Якын киләчәктә мондый кабинетларның саны тагын да артачак.

чәк-чәкне күргәч авыл, әни искә төште. Тик үзем пешерә белмим. Чәк-чәк ясарга өйрәтсәгез иде.

Равилә ШӘРИПОВА.
Пермь шәһәре».



Җылымса сөткә йомырка сытып, тоз, шикәр салып әйбәтләп болгатыгыз, он салып йомшак камыр басыгыз. Аннан камырны вак кисәкләргә бүлегез, тәгәрәтеп, 1 см калынлыгында итеп «таякчыклар» ясагыз. Эрбет чикләвеге зурлыгында итеп төш кисегез, аларны кайнап торган майга салып, алтын-сыман төскә кергәнче кыздырып алыгыз.

Аерым савытта бал белән шикәр кайнатыгыз. Балның кайнавы җитүен белү өчен шырпы очын кайнап торган балга манып алыгыз. Шырпыдан агып төшкән бал суынгач катса, балны кайнатуны туктатыгыз. Пешкән төшне киң савытка салып өстенә кайнар балны сибеп, әйбәтләп болгатыгыз, Аннан чәк-чәкне икенче савытка салыгыз, кулыгызны салкын суга тыгып алыгыз да чәк-чәкне үзегезгә кирәкле формага китереп өеп-төзәтеп куегыз. Әзер чәк-чәкне монпаси яки төрле төстәге вак борчак конфет белән бизәгез.

1 кг чәк-чәк ясау өчен 4 йомырка, 65—70 г сөт, 20 г тоз, камырга 10 г шикәр, 400 г югары сортлы он, чәк-чәкне кыздыру өчен 210 г сары май, 370 г бал һәм 90 г шикәр, 30 г монпаси яки конфет кирәк.

Киемдәге майлы буяу тапларын бетерү өчен тигез күләмнәрдә нашатыр спирты, бензин һәм скипидар катнашмасы кулланыла. Таплы урынга шушы катнашманы сөртеп, 20—30 минут тотарга. Буяу җебегәч, пычак сырты белән кырып алырга, калган тапны кайнар су белән юарга кирәк. Яңа гына тамган майлы буяуны керосинлы мамык кисәге белән бетереп була. Соңыннан нашатыр спирты белән чистартырга. Искергән майлы буяу табын шулай ук скипидар ярдәмендә бетереп була. Буявы изрәгәч, аны чәй содасы эремәсе белән чистартырга, аннан җылы су белән әйбәтләп юарга кирәк.

Корым, күмер, сумала, бензин һәм аяк киеме кремы тапларын бетерү. Корым һәм күмер тапларын скипидар белән бетерәләр. Искергән тапны бетерү өчен скипидарга йомырка сарысы кушып болгатыгыз, аны җылытыгыз һәм шушы катнашма белән бик әйбәтләп ышкыгыз. Аннан әйберне сабынлы җылы суда юып, әйбәтләп чайкатып киптерегез. Сумала һәм бензин табын бетерү өчен берәр бал кашык ак балчык һәм бәрәңге крахмалы алып, шуңа скипидар кушып ботка сыман масса ясагыз, берничә тамчы нашатыр спирты кушыгыз. Шушы катнашманы таплы урынга сөртеп куегыз, кипкәнен кәтегез, аннары щетка белән чистартыгыз. Киемдә катнашмадан сары тап калса, водород перекисе белән сөртеп агартыгыз. Аяк киеме кремы табын бетерү өчен 1 стаканга бер балкашык исәбеннән чәй содасы яки берничә тамчы нашатыр спирты салынган кайнар суда сабынлап юыгыз.

Язу карасы табын ничек бетерергә!

Әйбергә язу карасы тамса, аңа шунда ук тоз сибеп лимон согы сөртегез, аннан әйбәтләп чайкатыгыз. Ак әйбергә тамган кара табы өстенә бура сибәргә һәм водород перекисе белән чылатырга, аннан соң юарга кирәк. Киҗе-мамык, җитен, йон һәм ефәк тукымалардагы яңа кара тапларын спирт һәм аш серкәсе эссенциясе (бер өлеш эссенциягә ике өлеш су) яки аш серкәсе эссенциясе һәм динатурат катнашмасы (бер өлеш эссенциягә бер өлеш динатурат) белән бетереп була. Әйбернең язу карасына буялган урынын карасы эреп беткәнче берничә мәртәбә кайнар аш серкәсенә тыгып алырга, соңыннан кайнар суда юып чайкарга кирәк. Төсле тукымадагы күптәнге кара тапларын бетерү өчен башта аны нашатыр спирты һәм скипидар катнашмасы (бер өлеш спиртка бер өлеш скипидар) белән чылатырга, карасы җебегәч, әйберне яхшылап юарга һәм чайкарга кирәк.

Ак тукымадагы тутык табын гидросульфит эремәсе (1 стакан суга 10—20 грамм) бик тиз бетерә. Эремәне 60—70 градуска кадәр җылыталар да шуңа таплы тукыманы салалар, берничә минуттан алып җылымса суда чайкыйлар.

Төсле тукымалар өчен гидросульфит эремәсе ярамый, ул буяуның төсен ала. Гидросульфит химикатлар сатыла торган кибетләрдә була. Тукымада тутык табы бик күп булмаса, аны башка юл белән дә бетерергә мөмкин: таплы урынны берничә тапкыр лимон согы белән чылатырга, аннан үтүкләргә (тик кибеп җиткәнче үтүкләргә түгел), соңыннан су белән юарга кирәк.

* * *

Суыткыч исләнсә, 1—1,5 килограмм арыш ипиен кисәкләргә турап, суыткыч киштәләренә тезеп куегыз. Суыткычны бер тәүлек ябып тотыгыз — анда берниндн начар ис калмый.

Баш редактор —
В. Ф. Ихсанова.

Редколлегия членнары:
Н. З. Закирова
Ә. Ш. Мусина
Л. М. Мәһдиева
И. Г. Сункишева
С. Г. Сөләйманова
К. Г. Шәмсетдинова
Г. Ш. Шәрәфетдинов
(баш редактор урынбасары)
И. Г. Юзеев
З. Н. Якубова
Р. А. Җиһаншина

Художник
Х. Әхмәтҗанов.

Техник редактор
Э. Әдиатуллина.

Общественно-политический
и литературно-художественный журнал
«Азат хатын»
(«ОСВОБОЖДЕННАЯ ЖЕНЩИНА»)
на татарском языке.

Производствога бирелде 10/I-1979 ел.
Басарга кул куелды 26/II-1979 ел.
Тираж 352.000.
Заказ В-446.
ПФ 07019.
Кәгазь форматы 60×90 1/8.
Күләме 3 басма табак.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан,
Декабристлар урамы, 2.

ТЕЛЕФОННАР:
хатлар һәм авыл хуҗалыгы бүлекләре — 3-07-46;
промышленность, пропаганда, әдәбият һәм сәнгать бүлекләре — 3-07-42;
художник — 3-07-44;
фотокорреспондент — 3-07-67;
баш редактор урынбасары — 3-57-69;
кабул итү бүлмәсе — 3-07-40;
баш редактор — 3-38-75.

БЕЗНЕҢ АДРЕС:
г. Казань — 420066,
ул. Декабристов, 2
редакция журнала
«АЗАТ ХАТЫН».

(Ахыры. Башы 20 биттә.)

шыңны сагындым.— Ул кинәт нелде дә Халисәнең тезләрен кочаклап алды.— Гафу ит... Яратам сине, Халисәкәй. Бары сине генә — ышанасыңмы? Без бик матур яшәрбез!

— Әти килде, әти! — Комда пычранган бала куллары Вәкилнең муенына сарылды.— Бөтенләй килдеңме, әтием? Китмисеңме? Әйеме?

«Аһ, вакытсыз кердең, улым. Аһ»

— Бар улым, тагын урамда бераз уйна. Әтиең белән мица сөйләшергә кирәк.

— Әйе, улым, сезнең янга бөтенләй кайттым. Хәзер менә әниең белән минем китапларны гына барып алабыз да... Бар, улым, әниеңне тыңла, син без кайтканчы урамда уйнап тор! — Халисә аны-моны әйтергә өлгергәнче баланың башыннан сыйпап озатты да, Вәкил кабат хатынына борылды.— Әйдә, Халисәкәй, китапларны барып алыйк та... Ул хатын янына ялгыз гына барырга куркам мин.

«Юк» дип әйтергә көче җитмәде Халисәнең. Йөрәген авырттырып теге чактагы үз сүзләре исенә төште: «Ә сез, сеңлем, бала күтәреп ялгыз калуны күзаллыйсызмы?»... Әйе, әйе. Барырга кирәк. Ничегрәк каршылар икән ул? «Алдама үз-үзеңне,— диде бик еракка яшеренгән бер хис.— Син аны әле һаман да яратасың. Баруыңның сәбәбе дә шунда».

Луиза бала имезә иде. Керүчеләрне күргәч, йөзе кинәт кенә ап-ак булды. Нидер әйтергә теләгәндәй, иреннәре дерелдәде.

Вәкил ашыга-ашыга чемоданын җыйды, китапларын бәйләде.

Көнләшү һәм әрнү аша Халисә балага текәлде. «Ул». «Аныкы кебек үк кара чәч».

— Рәнҗемә, сеңлем, язмыш безне менә кабат очраштырды бит,— диде Халисә, ниһаять.— Ана булуың — үзе бер батырлык инде ул...

Эндәшмәде Луиза. Акланмады да. Баласын төреп аларны озата чыкты.

Илле метрлап ара үткәч, Халисә борылып карады.

Өйалды ишегенең яңагына сөялеп, бала күтәргән Луиза тора иде.

«Кабахәт. Луизаның иң авыр вакытында ташлап качасың. Кеше бусагасында ун көнлек бала белән калдырып. Иң авыр вакытымда миннән качкан күк»...

Юк. Халисә боларны кычкырып әйтмәде. Аяклары да «шушы кеше» белән рәттән атлый бирде.

Вәкил командировкадан кайтты. Балаларның бәхетле авазларыннан бүлмәләр тулды. Тәүфыйк әтисе алып кайткан яңа конструкторын алып үз бүлмәсенә шылды. Игезәкләр Дилбәр белән Динә дә сөйләшә торган курчакларына ташландылар.

Киң елмаеп, бәхетле елмаеп, кресло эчендә Вәкил утыра. Телевизор карый. Кухняда эшен бетереп, Халисәнең чыкканын көтә.

Халисә кашык-савытларны кабат-кабат юа. Колагында иренең бүген әйткән сүзләре чыңлый: «Тагын бер генә сәгать күрмәсәм дә түзә алмас идем. Яратам сине, Халисәкәй, өзелеп яратам». Ә теге чакта, ди йөрәк сыкрап, ә теге чакта син башкача сайрый идең бит! «Тормыштагы иң олы ялгышуым минем сиңа өйләнүем булган». Бу сүзләрнең дә онытылганы юк. Муенында иренең кайнар сулышын тоеп, Халисә кулындагы чынаягын төшерде. Челпәрәмә килде фарфор...

Шәһәр читендәге йортларның бер бүлмәсендә ятим малай үсә. Мәхәббәт җимешеме ул? Алай булса, ник атасыз үсә бала? Кем гаепле моңа? Кем? Вәкилем, улым, дип, үз-үзен онытып, алар сулышы белән яшәгән, мәхәббәте хакына, баласы хакына ирен ярлыкавы өчен инде үзен битәрләүче Халисәме? Әллә сөю-сөелү көткән, бу өлкәдә явызлык барлыгына әле инанмаган гөнаһсыз кыз, инде биш яшьлек бала анасы, бүген бәйрәмнәрне яратмаучы, ирләргә бүтән ышанмаучы ялгыз хатын Луизамы? Әллә тормыштан, үз-үзеннән бик канәгать Вәкилме?

«Азат хатын» ярдәм итте

— Журналның узган елгы июль санында сугышчан дусларымны эзләп язган хатым басылган иде. Иптәшләремнән хатлар алгач, шатлыгымны сезнең белән дә уртаклашасым килә,— дип яза Кизель шәһәреннән Факия Әскәрова.— Фронтташ дусым Мәүҗидә Гомәрова Башкортстанның Туймазы районы, Кандра станциясендә яши икән. Егерме тугыз ел совхозда эшләп, хәзер ялга чыккан. Сәйдә Латыйпова Башкортстанның Приютово поселогында яши. Аларның да тормышлары әйбәт. Дусларым белән хәбәрләшү миңа олы бәхет булды.


Бәлки ярдәм итәрсез?

— Хөрмәтле редакция! Мин бер больницага авыруларның хәлен белергә йөрим. Анда Татарстанның Апас районы, Балыкчы авылыннан Шәрифулла Хәлимуллин дә бар. Ул 1931 елдан 1939 елгача Мәскәүдә түбәндәге адрес белән яшәгән: Шоссе энтузиастов, д. 139-Б, общежитие завода нефтегаз. Бәлки аның туганнары шушы адрес буенча исләренә төшерерләр, — дип яза Мәскәү шәһәре, Туристическая урамы, 19 нчы йорт, 1 нче корпус, 102 нче квартирада яшәүче Сания Фәхретдинова.

— Бу больницага икенче бер кешене Сәйфулла Сәйфулловны сугыш вакытында госпитальдән китергәннәр. Янына утырып, мин аны ашатам. «Рәхмәт» сүзеннән башка бер сүз дә сөйләшми ул һәм бернәрсә дә хәтерләми. Ул — уртача буйлы, 52 яшьләрдә булыр... Бәлки Сәйфулланың әти-әнисе исәнләр, һаман да газиз улларын көтәләрдер,— дип тәмамлый үзенең хатын Сания Фәхретдинова.



Башкортстан моделъерлары ижатынан



ТЫШЛЫКНЫҢ БЕРЕНЧЕ БИТЕНДӘ: Уфа Пионерлар йорты каршындагы түгәрәккә йөрүче балалар ясаган курчаклар.

Рифкат **ЯКУПОВ** фотосы

ТЫШЛЫКНЫҢ ӨЧЕНЧЕ БИТЕНДӘ: бу киемнәр Уфа модельләр йортында әзерләнгән.

Рифкат **ЯКУПОВ** фотосы

ТЫШЛЫКНЫҢ ДҮРТЕНЧЕ БИТЕНДӘ:

Рифкат **ЯКУПОВ** фотосы

Бәясе 20 тиен.
Индекс 73002.

ЯЗ

Фәннур САФИН

Түбәләрдән җиргә төбәлгән
Боз-сөңгеләр эреп актылар.
Җанда олы утка әйләнде
Күзләрдәге нәни чаткылар...

Җанландырып син, яз, кояшның
Төшкә генә кергән сурәтен,
Кирәк чакта җанны җылыттың,
Син кешеләр кебек икәнсең...